ЧИРАТТАН ТЫШ
Россия Дәүләт Думасы утырышында мөһим карарлар кабул ителде
> 2

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК
«ВТ» укучыларының күңелендә сакланган хатирә-истәлекләре
> 3

АВЫЛ ИМАМЫ
«ВТ» укучыларының саладагы дин әһелләре турында язмалары
> 5

МАЧ ӘЙТКӘН!
Кызык-мызык, булмас димә, фототөрткеләр – монда
> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 101 (28874) | Шимбә | 16 июль | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

УНҖИДЕ МЕҢГӘ – БЕРӘҮ

ТАТАР ТЕЛЕННӘН ИМТИХАН БИРГӘН ӘДИЛӘ ШӘЙХЕТДИНОВАНЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ЧАКЫРДЫЛАР

Татарстан Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов, татар теленнән республика сынавын тапшырган бердәнбер укучы – Балтач районының Норма мәктәбендә белем алган Әдилә Шәйхетдинова һәм аның укытучысы Энҗе Әсәдуллинаны Дәүсоветка очрашуга чакырып, Рәхмәт хатлары тапшырды. Нигә бер генә, башкалар кайда?

Татар теленнән республика сынавын тапшырган бердәнбер укучы Әдилә Шәйхетдиновага бу көннәрдә игътибар аеруча артты. Шулай зурлап, сине Дәүләт Советына чакырсыннар әле! Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин да килгән иде анда. Балтач кызының бу гамәле сокландыра, әлбәттә. Ул булмаса, берәү дә булмас, бигрәк көлке булыр иде бит. Сүз монда бердәм республика сынавы (БРИ) турында бара. Тик татар теленнән имтихан бирүчеләр тагын бар әле. Бүген КФУның милли бүлегенә укырга керергә теләк белдергән 170 абитуриент татар теленнән сынау тапшыра.

Татар телен белү зур дәрәҗәгә әйләнде бүген. Югыйсә без, татар кешеләре, туган телебезне белергә тиеш. Аңлашыла, бу очракта Әдилә Шәйхетдинова үрнәк күрсәтә. Ни өчен Арча, Актаныш районнары үрнәк күрсәтми?

– Бу халкыбызның күңел халәте, аның хәзерге торышына бәйле. Үзебез татар теле, мәдәниятебез, тарихыбыз, дибез… Менә шуннан чыгып, нәтиҗә ясарга була инде. Бүгенге халәт белән бер дә килешеп булмый, әгәр ризалашабыз икән, киләчәккә юлыбыз тарайганнан-тарая бара дигән сүз бу. Быел республикада 17 меңнән артык (былтыргыларын да исәпләп) чыгарылыш укучысы имтихан тапшырды. Шулардан бары бер кыз – Балтач районының Норма мәктәбе укучысы Әдилә генә татар теленнән имтихан сайлады, – диде Илсур Һадиуллин. – Әлеге сан елдан-ел кими. «Монда кем гаепле соң?» – дип сорыйлар. Бары тик үзебез генә, бер кешене дә гаепләргә кирәкми. Димәк, без, әти-әниләр, укытучылар, массакүләм мәгълүмат чаралары, халкыбыз… Телебезгә булган мөнәсәбәтебезне күрсәтүче бер фактор булып тора бу. Моның белән мактанырга ярамый, киресенчә, көенергә кирәк.

Татар теленнән имтиханны шулай аз укучы сайлау югары уку йортларына кергәндә туган телдән дәүләт имтиханы булмауга бәйлеме?

– Кирәк әйбер. Вузда исәпкә алынса да, начар булмас иде. Ләкин ул – саламга тотыну гына, минемчә. Иң беренче чиратта, күңелдә булу кирәк. Рухи ихтыяҗ булу, гаиләдә, әти-әниләрдән, әби-бабайлардан килгән бер төрле татарлыкның яшәве мөһим, – диде Марат Әхмәтов.

Марат Әхмәтов белдергәнчә, киләсе елда татар теленнән сынау бирүче дистәләгән, йөзләгән укучы кирәк. «Республикада туган телдә имтихан бирү дәрәҗәле, кирәкле әйбер булырлык итеп, кызыксындыра торган ниндидер чаралар турында уйлыйсы булыр», – диде ул.

Имтиханны бер генә бала тапшыргач, күпләрдә башка сорау туа: «Мәктәпләрдә физика, математика, химия кебек фәннәр укытучыларын каян табарбыз?»

Илсур Һадиуллин моңа да үз җавабын биреп үтте. Министр әйтүенчә, татар теленнән имтихан бирү – безнең укучылар математика, химия, тарихны, башка фәннәрне белми, татарча укытырга әзер укытучылар булмаячак, дигән сүз түгел.

– Татар теленнән имитихан бирүче берәү генә булу белән укытучылар әзерләүне бутарга ярамый. КФУга ел саен тарих һәм чит тел, химия һәм чит тел, физика һәм чит тел һәм башка юнәлешләр буенча 150 абитуриентны кабул итәбез. Анда ике белгечлек алып чыгалар. Узган ел югары уку йортларын 150 укытучы тәмамлады. Без аларның барысын да эшкә урнаштырдык, – ди министр.

Тик башка проблема да бар. Уку йортларына максатчан юллама белән укырга кергән яшь белгечләр (целевиклар) үз районнарына эшкә кайтырга теләми икән. Министр әйтүенчә, мең дә бер сәбәп табалар икән.

– Максатчан уку юнәлешенә ни өчен барырга теләмиләр? Былтыр 312 бюджет урынының 198е көндезге бүлеккә бирелсә, шуның 99ына гына кабул иттек. Монда бит стипендия дә түләнә. Яшьләрнең үзләренә йөк аласы килми. Шуңа күрә мәктәпләрдә ел башында 2 меңгә якын укытучы җитми. Без педагогик уку йортларыннан 4 меңгә якын укытучы әзерләп чыгарабыз, әмма ике меңлек бушлыкны ябып бетерә алмыйбыз. Бу бик куркыныч, – ди Илсур Һадиуллин.

Әдилә исә документларын КФУның «татар һәм рус теле укытучысы» юнәлешенә тапшырган. Студент булу өчен баллары җитә дип саный. Дөрес, әле вузларда нәтиҗәләр соңрак билгеле булачак. Энҗе Әсәдуллина аннан шәп укытучы чыгар дип ышана. «Мәктәп җитәкчелегеннән рөхсәт сорап, Әдиләдән дәресләр укыттырып карадым. Дәреснең бер минутын да әрәм итми. Балалар да бик яратты үзен. Диплом алгач, минем урынга кайтыр дип ышанам», – ди остазы. Әдилә дә кырт кисеп: «Мин үз мәктәбемә татар теле укытырга кайтачакмын!» – ди.

Сәрия МИФТАХОВА

Без – беренче урында

Татарстан биш ай йомгаклары буенча сәнәгатьтә җитештерү индексы ягыннан Идел буе федераль округы төбәкләре арасында беренче урынга чыккан. Татарстанстат хәбәренә караганда, әлеге индекс узган елның шушы ук чорына карата 108,4 процент тәшкил иткән. Республика бу күрсәткеч буенча төзелеш, торакны файдалануга тапшыру, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, ваклап сату өлкәсендә сәүдә әйләнеше кебек тармакларда алдынгылыкка чыккан. Икенче урында – Түбән Новгород өлкәсе. Удмуртия – өченче.

Иделне савыктыралар

Татарстанда «Иделне савыктыру» проектын гамәлгә ашыруга 2024 елга кадәр 18 миллиард сум чамасы акча тотылачак. Шуның 13 миллиарды – федераль бюджет акчасы. Экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков әйтүенчә, проектның төп максаты – Иделгә агызыла торган пычрак су күләмен өч тапкыр киметеп, төп елгабызның экологик хәлен яхшырту. Моның өчен бездә 13 чистарту корылмасы төзү һәм искеләрен төзекләндерү, табигатькә зыян китерүче чүплекләрне юкка чыгару планлаштырыла. Татарстанда ун муниципалитетта 12 чистарту корылмасы төзелгән һәм төзекләндерелгән инде.

Узган ел Казанда канализация суларын биологик чистарту корылмалары яңартылган. Канализация суының Иделгә агызыла торган шакшы күләмендәге өлеше 42 процент тәшкил итә. Шулай ук Куйбышев сусаклагычында бәдрәф шакшыларыннан торучы ләм кырларын юкка чыгару дәвам итә. Моның өчен 8 миллиард сум тотылачак. 100 гектар мәйданда 4 миллион кубометрдан күбрәк күләмдә утырма җыелган. Сусаклагыч Татарстанда 900 меңнән артык кешене су белән тәэмин итә.

Бәяләр төшкән

Бер атна эчендә – 1–8 июль аралыгында республикада кайбер яшелчә һәм җиләк-җимеш, шулай ук шикәр комы, карабодай бәяләре төшкән. Татарстанстат мәгълүматларына караганда, кәбестә бигрәк тә нык арзанайган: 17 процентка кимеп, килосы 31 сумга калган (37 сум булган). Моннан тыш бәрәңге очсызланган: 54 сум булса, хәзер 49 сум. Помидор хакы 7 процентка кимегән (97 сум). Банан 3 процентка арзанаеп, килосы 94 сумга калган. Шикәр комы (70 сум) һәм карабодай бәясе (114 сум) 1,5 процентка төшкән. Ә менә кишер, киресенчә, кыйммәтләнгән (1,5 процентка – килосы 58 сумга җиткән). Сыер ите (килосы 478 сум) һәм дөге (98 сум) бәясе арту да күзәтелә.

Коенмавың хәерле

Татарстанның биш комлыгында, суның сыйфаты начар булу сәбәпле, ял итмәвең хәерле. Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсеннән хәбәр ителгәнчә, җәен республикада 18 пляж ачу күздә тотылган булган. Бүгенгә аларның 11е генә эшли. Бишесе – Казанда («Локомотив», «Нижнее Заречье», «Комсомольский», Зәңгәр күл һәм Зур Аккош күле). Түбән Камада, Чаллы, Әлмәт, Лениногорск, Зәй һәм Яшел Үзәндә берәр комлык ачылган.

Роспотребнадзор идарәсе һәр атна саен пляжларда суның сыйфатын тикшереп тора. Соңгы мәгълүматларга караганда, белгечләр Казандагы «Локомотив», «Нижнее Заречье», Зур Аккош күле комлыкларының, шулай ук Минзәлә пляжының тиешле санитария-гигиена таләпләренә туры килмәвен ачыклаган. Моннан тыш Зәңгәр күлдә микробиологик күрсәткечләр начар булып чыккан. Шул ук вакытта суда вируслар, паразитлар, радиация табылмаган. Таләпләргә туры килмәгән урыннарда су коену киңәш ителми.

Яшенле, яңгырлы җәй

Татарстанда эссе һаваны яшенле яңгырлар, көчле җил алыштыра. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, шимбә – 16 июльдә көндез +24…+29 градус, кыска вакытлы яшенле яңгырлар булачак. Төнлә +14…+19 градус. Якшәмбе – 17 июльдә дә урыны белән яшенле яңгырлар явачак. Көндез +24…+29, төнлә +14…+19 градус җылы. Синоптикларның башлангыч фаразларына караганда, киләсе атна башында – 18–19 июльдә һава торышы янә тотрыксыз: яшенле яңгыр, көчле җил көтелә. Дүшәмбедә көндезге сәгатьләрдә +24…+29, төнлә +14…+19 градус җылы булачак. Сишәмбе бераз җиләсләнә: көндез термометрның терекөмеш баганасы +21…+26 градусны күрсәтәчәк.

Яңалык

Ташлама чүп – штрафы күп

Автомобиленнән чүп ташлап калдырган кешеләргә 200 мең сумга кадәр штраф салырга, ә автомобильләрен конфискацияләргә дә мөмкиннәр. Россия Президенты Владимир Путин шул уңайдан яңа закон имзалады.

vk.com

Татарстанда бу эшне экологлар башкарыр дип көтелә. Татарстанның Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының матбугат үзәге җитәкчесе Елена Веселова сүзләренә караганда, чүп ташлаучыларны камера ярдәмендә ачыклаячаклар. Аларны чүп җыелган урыннар тирәсенә куярга дип исәпләп торалар.

«ЧИСТАБУЛАЧАК» экологик хәрәкәте активисты Алинә Шәймәрданова да чүп ташлаучыларга штраф күләме арткач, бәлки, аларның саны кимер дигән өметтә.

– Һәркем җаваплы булырга тиеш. Кайчакта кеше артыннан чүп җыеп йөргәндә, ачу да килә. Без бит табигатьне пычратып кына калмыйбыз, андагы тереклеккә дә зур зыян салабыз. Чүпнең үз урыны бар аның. Мондый закон күптән кирәк иде, – ди ул.

Татарстанның Урман хуҗалыгы хезмәткәрләре урман һәм юл буйларына чүп ташлаган кешеләрне фотога төшерә торган махсус җиһазларны берничә ел элек куя башлаганнар иде инде. Ул чакта алар урманга зыян салучыларны ачыклады. Казандагы шәһәр яны урманчылыгы җитәкчесе Илнур Кәшәфиев сүзләренчә, урманчыларның үзләренә генә юл буендагы тәртипне саклау кыенрак булган. Чөнки чүп ташлаучыны эләктер өчен, камераны ераграк урнаштырырга кирәк икән. Аның өчен җавап бирүче кеше булмагач, күрсәтеп куярга да ярамаган.

– Ул җиһаз 25 метр арадан төшерә иде. Аны без агач арасына качырып кына куйдык. Камераларны ватып китү очраклары да булгалады. Бу яңалыкка шатландык. Димәк, тәртип булачак, – ди ул.

Урманчы сүзләренчә, алар куйган җиһаз елына табигатькә зыян салучы 7–8 машина йөртүчене генә тоткарларга булышкан. Хәзер инде яңа камералар куелып, табигатькә зыян салучыларны күбрәк ачыклап булыр, дип өметләнә ул.

Яңа закон буенча, автомобильдән яки мототранспорт чарасыннан ярамаган урында чүп ташлаган өчен гражданнарга – 10–15 мең сум, вазыйфаи затларга – 20–30 мең сум, юридик затларга 30 меңнән 50 мең сумга кадәр штраф салыначак. Кабат хокук бозган өчен транспорт чарасын конфискацияләү белән бергә икеләтә күләмдә штраф каралган. Әгәр бу кагыйдәне йөк автомобильләре, тракторлар яки тагылма арбалар бозса, гади гражданнарга – 40 меңнән 50 мең сумга кадәр, вазыйфаи затларга – 60 меңнән 80 мең сумга кадәр, юридик затларга 100 меңнән 120 мең сумга кадәр акчасын чыгарып бирәсе була. Тагын шунысы бар: йөк машинасын конфискацияләргә дә мөмкиннәр.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сүзгә-сүз

Лилия ГОМӘРОВА, Федерация Советының Фән, мәгариф, мәдәният комитеты рәисе:

Мәктәпләрне саклау мәсьәләсе актуальлеген югалтмады. Әмма Росгвардия хезмәтеннән барлык мәктәп һәм бакчалар да файдалана алмый, бу шактый чыгымлы. Бу проблеманы хәл итүнең берничә юлын карадык. Мәсәлән, сак хезмәтенә чыгымнарны бердәм оешма ярдәмендә киметергә мөмкин. Хәзер шундый механизмнарны эшлибез.

(«Парламентская газета»дан)

ТУҢДЫРМА ХАКЫ

«Аргументы и факты» газетасы мәгълүматларына караганда, бүген Россиядә туңдырма җитештерә торган 200ләп оешма бар. Барыбыз да яраткан татлы ризыкның бәясе нинди өлешләрдән җыела соң?

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Отличниклар һәм хулиганнар

Без яшәгән дөнья ник һаман камиллектән ерак? Ник кешелек тарихы – сугышлар тарихы? Ихтимал, хикмәт Җирдәге бүгенге процессларның үзәгендә торган кеше затының, билгеле бер күләмдәге зиһенгә ия булу сәбәпле, кыргый табигатьтән аерылып чыгып, артык көчәюендә, ләкин иләһи чын кеше булыр – үзе кебекләр белән, табигать белән гармониядә яшәр дәрәҗәгә җитмәвендәдер. Ихтимал, илләр, дәүләтләр башына һаман да гаделлекне, намусны кыйбла иткәннәрнең түгел, ә элеккеча, агрессив һәм мин-минлекле, бары көч белән генә исәпләшкән кабилә, өер башлыклары, шуларның прототиплары килүендәдер. Ягъни кешелек – әлегә ниндидер аңлаешсыз ярымфабрикат, иптә акыл иңмәгән тәртипсез бер үсмер...

Сыйныфтагы яхшы укучылар санының билгеле бер проценттан артмаганын һәр укытучы белә. «Бишле» генә алып укыганнар укучыларның якынча уннан берен тәшкил итә, диләр. «Ни өчен?» дигән сорауны куйганчы, «Кем ул отличник?» дигәненә җавап бирел карыйк. Ул – аң-белемгә, фәннәрне үзләштерүгә сәләте һәм дәрте булган бала. Бер үк вакытта ул – кечкенәдән дөрес тәрбия алган, ата-анасы, укытучыларны хөрмәт иткән, әйткәнне тыңлаган тәртипле яшь кеше. Андыйларны гадәттә бер сүз белән «акыллы бала» дип атыйлар. Акыллы, чөнки өйдә дә, мәктәптә дә проблемалар тудырмый, кирсенчә, мактала, үрнәк итеп куела, гомуми күрсәткечләрне югары тота.

Һәр сыйныфта әле тагын күпчелекне тәшкил итүче урта укучылар һәм дә сан ягыннан отличниклардан ике-өч тапкыр күбрәк «өчле капчыклары» була. «Өчле капчыклары» арасында ярыйсы тәртипсез, мәктәп директоры да танып ала белгән бер-ике хулиган да укыган булып йөри. Сыйныфтагы мондый бүленеш, мондый спектр, әлбәттә, табигатьтән, геннардан һәм тәрбиядән килә. Һәм анда, киләчәккә карап сүз йөрткәндә, без белгән сәер бер закончалык бар: шул «өчле капчыклары» һәм хулиганнарның билгеле бер өлеше тормышта отличникларга караганда күбрәккә ирешә, югарырак күтәрелә. Ни өчен? Чөнки, гади итеп аңлатканда, мәктәптәге отличник тормышта да отличник булып кала – тәртипле, гаделлек яклы, тыйнак. Шомалык минималь, алдаша белми, хәйлә, үткерлек җитенкерәми. Отличниклардан гадәттә төрле өлкәләрдәге яхшы белгечләр, галимнәр, фикер ияләре чыга. Тик менә «өчле капчыклары» аерым очракларда, әйткәнебезчә, купкә югарырак та сикерә – алар кеше, халык язмышын хәл итүче вазыйфаларга да ирешкәләп куя.

Ирешми ни, без яшәгән җәмгыять үзе дә үзенчәлекле, анда һаман да «хәйләсез дөнья файдасыз», һаман да «юаш булсаң, басалар». Гадел, «дөрес»ләр өчен түгел хәзерге мохит. Анда үткерләр, әрсезләр, хиссезләр тантанасы. Җәмгыять, зурдан алганда, нәкъ менә шул «көчле өчле»гә барганнар, хәттә ки хулиганнар өчен. Андыйлар бит, класссик әйтмешли, «түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелгән». Фәннәрне белмәсәләр дә, тормышны, адәми затлар арасындагы мөнәсәбәтләрне алар барыбер яхшырак аңлый. Укытучыны тыңламый, әти-әни белән әрепләшеп үскән, физика белән тарихны куптан онытканнар гадәттә психологиядә көчле, телгә оста, алар кирәкле вакытта кирәкле сүзне әйтә, аның бәясен белә торганнардан. Ә җитәкче булу өчен тагы нәрсә кирәк? Карьера гына димәгән, шәхси тормышта да андыйлар бәхетлерәк кебек. «Ботан»нарны кызлар мәктәптә үк өнәми. Ә менә тәртипсезне ярата. Ни өчен икәнен ул үзе дә белми, әмма ярата.

Моның хикмәтен тагын да шул табигать, биология ачып сала. Нәсел калдырам дигәндә, күндәм һәм тәртипле түгел, ә агрессияле, уҗат, кыю һәм тәвәккәл партнер сайланырга тиеш. Бу – барлык тере җан ияләре өчен дә закон. Башкача биологик төр бетәргә, юкка чыгарга мөмкин. Табигатьтән килгән бу шарт һәр ике җенеснең дә эчке аңына – подсознаниесенә салынган, программалап куелган. Шуңа кызлар, үзләре дә аңламастан, зоологлар әйткән башбирмәс «альфа-самец»ларга, шуңа якынныраға тартыла. Ул гынамы, егет чакта без дә, әтәчләнеп, кызлар өчен бәргәләшәбез. Табигать, эволюция кушкач, кыргыйлыктан чыгып җитмәгән, кая китәсең? Ускәндә поши үгезләренең, ана пошиларга хуҗа булу өчен, акны-караны күрмичә, бер-берсе белән сөзешкәнен машина әрҗәсеннән карап торган иста. Әлегешкән чатлы-ботаклы зур мөгезләр җир актара, көчле тояклар астында агачлар шартлап сына, куаклар таптала, киңәйгән борын тишекләреннән пар бөркелә – турнир, җиңүчене ачыклау бара. Приз – нәселне дәвам итү. Бу – табигать, бу – дөрес. Ә менә кешеләр арасында агрессиясе, усаллыгы күбрәк булганнарның өскә чыгуы балагә түгел микән? Адәми затлар агрессиядә, көчтә түгел, ә акыл, гыйлем дәрәҗәсе буенча бил алышсалар, дөресрәк булмас идеме? Дәүләтләр белән дә «альфа-самец»лар түгел, элекке отличниклар идарә итсә, дөнья гел башка булмас идеме? Ихтимал, булыр иде.

Кеше заты кыргый табигатьтән әле бер аяк белән генә чыккан. Әлегә без – көчеш чорында. Кеше дигән затның агач башыннан төшүенә җәмгыясы 10–15 мең ел. Эволюция өчен бик аз вакыт бу. Шунлыктан да тестостерон IQдан (интеллект дәрәҗәсеннән) кыйммәтрәк йөри. Шунлыктан кыз бала ярты сыйныфны кыйнап чыккан хулиганны якын итә. Шунлыктан хакимиятләрдә үзсүзле, усал, хәтта ки рәхимсез кешеләр күп.

Кучеш чоры күпме дәвам итәчәк? Аннан исән чыга алырбызмы? Кешене агач башыннан төшерү табигать аномалиясе, ялгышы булмаганмы? Бу сорау да урынлы. Чөнки планетадагы бүгенге миллион проблема, адәми заттагы төп әшәкелек – агрессия һәм мин-минлекне дә кертеп, кеше «агачтан төшкәнгә» һәм кеше булып җитә, гармония тудыра алмаганга бит. «Homo sapiens» урман аланында көчлене ачыклауда инде узган. Адәми затлар инде хәтсездән дәүләтләргә берләшкән. Алар идеология тудырырга, котык-пропаганда таратырга, иң әшәке коралар коярга өйрәнгән. Һәм шул коралларны кулланырга. Әгәр дә «кеше» дигән җан иясендә пошидагы мөгез иясә ертык җанвардагы тешләр генә булса, артык кайгырасы булмас иде. Тик кеше уйлап тапкан корал – үтерү җайланмаларының ассортименты бүген коточкыч күп. Чөнки шушы көнгәчә дәүләтләр башында акыллы «ботан»нар түгел, кеше башыннан йөри белгәннәр күбрәк. Өстенлек яратхан, мин-минлекле, кайсылары инде картаеп барган ул «үгезләр» шәхси турнир оештырмый, алар баштанаяк коралланган дәүләтләрне бер-берсе белән чәкештерә. Гади халыкка сугыш кирәкми. Ә «альфа-самец»лар сугышмыйча тора алмый. Сугыш, дошман эзләү, табу – алар стихиясе. Башкача аларга кызык түгел. Властька кичәге «ботаник»лар, яңа Марк Аврелийлар килгәнче шулай барачак. Исән калган тәкъдирдә, әлбәттә..

ЧИРАТТАН ТЫШ УТЫРЫШТА

Дәүләт Думасында

Кичә Россия Дәүләт Думасы депутатлары чираттан тыш утырышка җыелды. Анда барлыгы 16 закон проекты каралды, шуларның алтысы кабул ителде. Моннан тыш, утырыш барышында кайбер түрәләр яңа вазыйфага да билгеләнде.

duma.gov.ru

Аерым алганда, утырышта илнең сәүдә һәм сәнәгать министры Денис Мантуров вице-премьер итеп билгеләнде. Россия Президенты Владимир Путин шул хакта указны имзалады да инде. Мантуров өчен 394 депутат тавыш бирде. Исегезгә төшерәбез: бернчә көн элек Россия Президенты хөкүмәттәге вице-премьерлар санын 10нан 11гә җиткерү турында указ имзалаган иде. Россия Премьер-министры Михаил Мишустин бу вазыйфага Мантуровны тәкъдим итте.

Билгеләнү дигәннән, шушы ук утырышта Владимир Путин Россия вице-премьеры Юрий Борисовны, вазыйфасыннан азат итеп, Роскосмосның генераль директоры итеп билгеләде.

Яңа вице-премьер үз чыгышында берочтан депутатларга параллель импорт турындагы законны тиз арада хуплаганнары өчен рәхмәт белдерде. Мантуров сүзләренә караганда, аның хисабына Россиянең тотылган машиналар базары кирәкле запчастьлар белән тәэмин ителгән. «Дөрестән дә, күп кенә чит ил оешмалары запчастьларны турыдан-туры кертүдән туктады. Әмма хәзер кирәкле компонент, агрегатларны безнең белән дустанә мөнәсәбәттә булган башка илләр аша кертеп була», – ди ул.

Мантуров сүзләренә караганда, быел Россиядә җиңел машиналар 50 процентка азрак җитештерелергә мөмкин. Мондый шартларда электрда йөрүче «тимер ат»ларга (электрокарларга) басым ясау яклы ул. «Аларга эчке янулы двигатель дә, ниндидер катлаулы механизм, күперләр дә кирәкми», – ди Мантуров.

Утырышта бернчә яңа закон да кабул ителде. Шуларның берсе ана капиталына кагыла. Аерым алганда, аны хәзер шәхси балалар бакчасы өчен түләүгә тотарга да рөхсәт ителәчәк. Әлеге закон проекты Дәүләт Думасына 2019 елның ноябрендә кертелгән иде. Проект авторлары фикеренчә, 2007 елда кабул ителгән хөкүмәт карары нигезендә ана капиталын мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы оешмалар күрсәткән хезмәт өчен тотарга рөхсәт ителә. Лицензиясе булган шәхси эшмәкәрләр ачкан балалар бакчалары исә бу исемлеккә керми иде. Хәзер исә алар күрсәткән хезмәтләр өчен дә ана капиталы акчасы белән түләп булачак. Билгеле булганча, беренче бала өчен бирелгән ана капиталы күләме – 483,8 мең сум, икенче баланыкы 639,4 мең сум тәшкил итә.

Утырышта кабул ителгән икенче бер закон варисларга кагыла. Хәзер аларга судта ата булуны дәгъвалау хокукы бирелә. Хәзерге вакытта туу турындагы язмалар кенәгәсендәге ата-ана хакындагы язуга карата бары тик шул кенәгәдә баланың әтисе яки әнисе дип күрсәтелгән затлар, биологик әтисе (әнисе), бала үзе яки аның опекуны, шулай ук карар кабул итәргә сәләтсез ата-ананың опекуны гына дәгъва белдерә ала. Ә үз әтисенең яки башка ихтимал варисның биологик яктан туган түгеллеген исбатларга тырышкан варисларның мөрәҗәгатен исә судлар кабул итми. «Шуңа күрә кенәгәдә баланың әтисе буларак язылган кешенең варислары үз хокукларын яклый алмый», – диелә законга аңлатма язуында.

Россия Дәүләт Думасы кичә тагын бер мөһим закон кабул итте. Украинадагы махсус операция барышында Россиягә коралды көчләр үтеп керүне булдырмаган чик сакчыларына хәрби хәрәкәт ветераннары статусын бирүне күздә тота ул. «Бирегә Россия – Украина чигендә һәм махсус хәрби операция барган зонага якын урнашкан чиктәш территорияләрдә мөһим бурычлар үтәгән Курыкчысызлык федераль хезмәте хәрбиләренә хәрби хәрәкәтләр ветераны һәм инвалиды статусын бирү турында сүз бара», – дип ачыклык кертте Дәүләт Думасы Спикеры Вячеслав Володин.

Сүз уңаеннан, киләсе елның февралендә Сталинград сугышында җиңүгә 80 ел тула. Владимир Путин бу датаны зурлап билгеләп үтәргә кушты. «Сталинград сугышында җиңүгә 80 ел тулу гә бәйле рәвештә чаралар әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты төзергә карар бирәм», – диде Президент бу уңайдан. Оештыру комитетын Россия Куркынычсызлык советы рәисе урынбасары Дмитрий Медведев җитәкләячәк.

Кичә Владимир Путин бонда складлары төзү турында да закон проекты имзалады. Чит илдән кертелгән товарлар шушы складка урнаштырылачак. Аларны таможняда теркәү эше исә интернет-мәйданчыклар аша башкарылачак. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов – мондый төр складлар төзү идеясен куәтләүчеләрнең берсе. 2022 елда ул, республиканың Россиядә беренче бонд складыны төзү тәҗрибәсендә катнашырга әзер булуын әйтеп, Россия Премьер-министры Михаил Мишустин исеменә хат юллаган иде. Бүген ул Кытай, Балтыйк буе, Казахстанда уңышлы гына эшләп килә инде. Рөстәм Миңнеханов ул чакта хатында илдәге интернет-сәүдәнең, нигездә, әнә шундый складлар булмау аркасында үсә алмавын искәрткән иде.

Татарстаннан бу проект өчен җаваплы зат итеп Татарстан Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукын яклау буенча вәкаләтле вәкил Фәрит Габделганиев билгеләнде. «Үз көченә кергән канун Россиядә бонд складлары төзү тәҗрибәсенә башлангыч бирә. Россиядәге иң беренче шундый склад якын киләчәктә Татарстанда булыр дип өметләнәбез. Соңгы елларда бездә әлеге проектны тормышка ашыру өчен барлык шартлар да тудырылды: югары әзерлекле логистика инфраструктурабыз бар, интернет-сәүдә базары үсештә, географик яктан да уңышлы урында урнашкан без, республика хакимияте да даими ярдәм кулы сузып тора», – диде ул үз чыгышында.

Шәһәр авылга якыная

Татарстан һәм Оренбург өлкәсе парламентарийлары җирле үзидарәнең бер баскычлы системасын оештыру мәсьәләләре буенча фикер алышты.

Кичә Абдулино шәһәрендә (Оренбург өлкәсе) Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты белән Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең Җирле үзидарә һәм дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеге мәсьәләләре комитетының берләштерелгән күчмә утырышы булды. Анда парламентарийлар җирле үзидарәне оештыруның бер баскычлы системасы мәсьәләләре буенча фикер алыштылар.

Мәгълүм булганча, Россия Дәүләт Думасы беренче укылышта «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» закон проектын кабул итте. Документ, бер баскычлы системага күчүне күздә тотып, илдәге җирле хакимият системасын сизелерлек үзгәртә.

Оренбург өлкәсендә бер баскычлы җирле үзидарә системасына күчү, ягъни шәһәр белән районны берләштерү моннан ун ел элек үк булган. Беренче үзгәрешләрне Абдулино шәһәр округы халкы күргән. Бүген Оренбург өлкәсенең алты муниципалитеты шул системага күчкән инде. Ике регионның закон чыгаручылары очрашуында үзгәртеп кору процессының хокукый һәм гамәли нечкәлекләре өйрәнелде.

«Берләшүнең зур өстенлеге – халыкның тормыш дәрәҗәсен тигезләү», – дип саный Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесе Рәисе урынбасары Александр Куниловский. – Фермерлар өчен грантлар алу мөмкинлекләре киңәйтелде. Шәһәр һәм авыл халкы да дәүләт программаларында катнаша ала. Шул ук вакытта шәһәр округларында авыл халкы өчен берләшүгә кадәр гамәлдә булган ташламалар, шулай ук ТКХ өлкәсендә тариф сәясәте сакланып калды. Җирле үзидарәнең бер баскычлы системасына күчү дәйлиләре ачык күренә. Башка муниципаль берәмлекләрдә дә шундый юлдан барачакбыз. Яңа федераль закон буенча 2028 елга кадәр барлык үзгәрешләр узачак».

«Бүген без шушы процессулар аша узган кешеләр белән аралаштык, Оренбург тәҗрибәсе игътибарга лаек, – дип басым ясады Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Юрий Камалтынов, – шул исәптән монда актив үсеш алучы старосталар институты. Безнең өчен бу – яңа әйбер. Бөтен тәбәкләргә җирле үзидарәнең бер баскычлы моделенә күчәргә туры киләчәк, һәм кече торак пунктларда старосталар яңа чынбарлыкта хакимият һәм халык арасында арадашчылар булачак».

«Җирле үзидарә системасын алга таба үстерү буенча фикерләр һәм конструктив сөйләшү, фикер алмашу булды, – дип ассызыклады Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты рәисе Альберт Хәбибуллин, уртак утырышка йомгак ясап. – Җирле үзидарәнең хәзерге системасы барлыкка килгәннән бирле, 1990 нчы еллар башында, безнең республика һәм Оренбург өлкәсе 131 нче федераль закон кысаларында һәм үз вәкаләтләре чикләрендә һәрберсе үз юлы белән барды. Минемчә, бер баскычлы системага күчкәндә, Татарстан Республикасы һәм Оренбург өлкәсе тәҗрибәсе территорияләрне алга таба үстерү өчен кирәк булачак».

Дәүләт Советының профильле комитеты рәисе билгеләп үткәнчә, Татарстан да, Оренбург өлкәсе дә федераль закон проектына үз тәкъдимнәрен юллаган. Ул киләчәктә аларның исәпкә алыначагына ышанычы белдерде.

КАРИЛЕНЕҢ РӘШИТЕ БАР

Менә шундый кеше

«Авылдан чыккан һәр түрә үз авылы турында гына кайгыртса да...» Газетабызда бернчә ел инде шушы фикерезнең хаклыгын раслардай язмалар дөнья күрә. Авыллар язмышына битараф булмаган, аларны яшәтү өчен кулыннан килгән кадәр матди һәм рухи ярдәмен күрсәткән андый кешеләр бик кадерле шул.

Балтач районы Кариле авылының да бар андый кешесе. «Безнең өчен Рәшит Мәгъсүм улы Ильясов – нык итеп сөялерлек алтын багана ул. Аның игелекле гамәлләрен санап чыгу өчен генә дә шактый вакыт кирәк булыр иде, – ди авыл өчен янып-көеп йөрүче Гөлсем Миңнебаева. – Бик күп авылдашларыбыз ул җитәкләгән районара юл төзү идарәсендә эшләп, яңа өйләр салды, яхшы машиналар алды – күп еллар буе зур хезмәт хакы түләп кенә түгел, кирәк чакта матди ярдәм күрсәтеп тә, ул эшчеләренә шундый мөмкинлекләр тудырды. Авылыбызның юллары асфальтланган, ул эшләткән Әниләр чишмәсеннән кеше өзелми, зират коймалары, Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар һәм катнашучылар хөрмәтенә төзелгән һәйкәлебез балкып тора, мәчетебез, мәдрәсәбез яңартылган. Авылыбызның зур тарихын туплаган, бик сыйфатлы һәм күләмле «Кариле – Кара иле» китабы дөнья күрде. 2015 елда Кариле мәдрәсәсенең 300 еллык юбилее республика күләмендә зур итеп үткәрелде. Аларның һәркайсына Рәшит Мәгъсүм улының саллы матди ярдәме керде. Клубыбыз, мәктәбебез дә һәрдаим аның ярдәмен күреп яши, авыл Сабан туен да ел саен зур матди ярдәм күрсәтә».

Ул – үзенчәлекле шәхес. Район юллар идарәсен җитәкли башлавына тиздән утыз ел тула. Аны әле шуның кадәр ел белгәм. Үзе турында, эше турында сөйләргә яратмый ул. Ирешкән уңышлары – күп еллар коллегалары арасында мактаулы, ике тапкыр республикада «Ел хәйриячесе», 2021 елда «Ел лидеры» булуы турында да якыннары гына белә. «Минем егетләр», – дияргә ярата ул. Оешма ирешкән уңышларны да аларның хезмәте итеп күрсәтә. «Иң яхшы шоферлар, иң яхшы тракторчылар бездә җыйналып калды», – ди. Инженер-техник белгечләрен дә, һәркайсы – үз эшенең остасы, һөнәри яктан бик тә әзерлекле хезмәткәрләр, дип мактый.

Бу сүзләрендә хаклык та зурдыр. Балтач – 1999 елда, республикада иң беренче булып, ул чактагы колхоз үзәкләрен асфальт юлга тоташтырган район булды. Коллективта һәркем үз урынында булмаса, мондый нәтиҗәләр булмас та иде. «1992 елда Россиядә Юллар фонды оешты. Мин эшли башлаган ел бу. 1999 елга кадәр яшәде фонд. Менә шушы еллар безнең күтәрелеш кенә түгел, сикереш ясаган еллар булды. Коллектив зурайды, матди база көчәйде, Чепьяда участок оештырылды, үзебезнең карьерны ачтык, республикада иң көчле оешмага әйләндек. Без ул елларда фантаҗарда эшләдек. Елына 30–38әр километр асфальт сала идек. Бу искиткеч зур саннар иде, башка мондый чор да, мондый нәтиҗәгә ирешкән коллектив та булмады. Ул чактагы район җитәкчесе Марат Әхмәтов та юл төзелешенә зур игътибар бирде. Район тарихында үзе бер чор булды ул...» – дип искә ала ул елларны язмам герое.

– Ул чакта машинада йоклап йөрдем дисәм дә, берниди арттыру юк, – дип дәвам итә әңгәмәдәшем. – Материал, чимал табу бик авыр иде. Түбән Кама, Әлмәт, Казан, Мари Иле, Киров… – эш барышын идарә итүгә карагнда, мин күбрәк материал, чимал юллау артыннан йөрдем. Берсеннән кайтып кердек, икенчесенә чыгып киттек… Алтышар ай хезмәт хакы түли алмаган еллар иде бит бу. Коллектив бетми калды…

Ә менә 1999 елдан соң инде коллектив өчен шактый авыр чор башлана (элекке иркенлек тагын ике генә ел дәвам иткәндә дә, районның барлык авылларын асфальтлы итәрлек куәтләре булса да). Дәүләт заказы да, дәүләт ярдәме да бетә. Әле генә гөрләп эшләгән техникалар тик тора, коллектив 171 кешедән 114кә кала. «Туннель»нең икенче башында аз гына яктылык күренсен өчен дә җитәкчелеккә күп тырышырга туры килә. Тик… инде бу этаптан исән-имин чыктык дигәндә, 2008 елдардагы илкүләм финанс-икътисад кризисы юллар төзелешен дә читләтеп үтми. Тагын эш фронты бетә. Монда исә алда алган чыныгулар ярдәмгә килә: узебездә эш көтеп ятудан банкротлыкка тиң икәнен аңлаган җитәкчеләр читтән эш эзли. Казан, Нократ Аланы, Сосновка, Мари-Төрек, Кукмара кебек шәһәрләргә барып эшлиләр. Тагын да ераккарак китәрләр иде – асфальты шуннан да еракка алып барып җиткереп булмый – суына. Коллектив инде моннан 8000 километр ераклыктагы Хабаровск – Чита юлы төзелешенә чыгып китәргә дә әзер була. Бәхетләренә, шул чакта республикада кабатган юл төзелешенә финансларны арттыра башлыйлар. Яңадан күтәрелеш чоры...

Дүртенче «удар» – финанс ягыннан иң көчлесе – «Татфондбанк»ка бәйле. Анда югалган миллионнар аяз көнне яшен сугуга тиң була. МДСУ моннан да исән чыга. Алай гына да түгел, «икенче сулыш»ы ачылгандай, һәр авырлыктан соң яңа бер таләпну белән эшли башлый. Соңгы дүрт-биш елда юллар төзелешенә, ремонтына игътибар тагын арта. Үзләре белән бергә эшнең сыйфатына таләпләр дә үзгәрә. Бу яңалыкка да әзер була коллектив – үткән ел заманча, экологик яктан уникаль булган яңа бетон-асфальт заводы эшли башлый. Ул яңа мөмкинлекләр ача.

– Әгәр дә гомеремдә нәрсәгәдер ирешкәнмен икән, бу уңышларда тормыш иптәшем Резеданың өлеше бик зур, – ди әңгәмәдәшем. – Һәрчак аңлап, һәр ситуациядә иң ныклы терәк-таяныч булды ул. Эше катлаулы, җаваплы булса да, гаилә аның өчен һәрчак мөһим. Без икебез дә бик хәрәкәтчән. Бергәләп җәяү дә йөрибез, чаңгыда, тау чаңгысында да шуабыз, башкасында да шөгыльләнәбез. Шөкер, балаларыбызга да дөрес тәрбия бирә белдек дип уйлыйм, алар өчен күңел тыныч…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

САЛАВАТСЫЗ КӨНЕ КӨН ТҮГЕЛ

Нияз исемле, авылда гомер итүче бик үзенчәлекле энем бар минем. Казанга елга бер генә килә, анысы да Салават концертын карау өчен. Шәһәргә борылып та карамас иде, әлеге дә баягы шул Салават концерты тарта аны. Үзе дә гармунчы булгангамы, концертны йотлыгып, илһамланып бер сулышта карый. Салават җырын тыңламаган көнен ул көнгә дә санамый.

Сәхнәгә чыгып Шәфәгать, Альфред, Илфат уйнаган гармуннарда уйнап карау теләге дә бар аның. Концерттан соң дисклар, китаплар сатып алып, Казан белән бер елга саубуллаша, авылга кайтып китә.

...Әллә вирустан курыкты, былтыр килмәде. Ул килмәгәч, без дә Салават концертына бармаска булдык. Әмма барасы килә... Көннәрдән бер көнне журналист Райнур Шакиров «Ватсап»ка язма җибәрде. «Концертында Салават синең белән булган бер кызык хәлне сөйли, ишеткәнең бармы соң?» – диелгән. Җырчының нинди кызык сөйләгәнен язмаган. Нәрсә булыр икән, мин әйтәм. Егерме елдан артык радиода эшләп, интервью алырга батырчылыгым җитмәгән, әмма бик хөрмәт иткән җырчым бит ул.

Күнегелгән гадәтне бозарга ярамый, барыйк, дидем иремә. Үзем куркам, үзем юртам дигәндәй, гадәтемчә, тиз генә САЛАВАТ сүзен расшифровать итеп шигырь язып, зур открытка ясатып алдык та киттек! Билетлар сатылып беткән... Әле ярый Камал театрында гел яхшы кешеләр эшли! Балконнан булса да урын табып керттеләр, һәм без елдагыча рәхәтләнеп тамаша карадык. Шикләнеп булса да сәхнәгә чыгып, открыткамны да тапшырдым. Зурлап, алкышларга күмеп рәхмәт әйтте Салават абый. Үз яхшылыгы үзенә кайтсын.

2004 елда булган хәл икән бу. Минем «Дулкын» радиосыннан «Татар радиосы»на күчкән, ә Салават абыйларның дөнья гөрләткән вакытлары.

Салават абыйларның бакчага барулары икән... Юлда радио тыңлап баралар. Радиодан мин сөйлим. Туры эфир вакыты булган, күрәмсең, бер ханым шалтыраткан һәм, бик борчылып, Әлфис Кыямовның арабыздан китүе хакында сөйләгән. «Шулкадәр сагынам, шулкадәр юксынам Әлфисне, берәр җырын куеп җибәрсәгез иде... Хәлемнән килсә, кире кайтарып, янымда җырлатып кына торыр идем үзен!» – ди икән радио тыңлаучы ханым. Ә мин, аны-моны уйламыйча, «Ярар, апа, хәзер сезнең сорау буенча, Әлфис Кыямов язмасында «Үзең кил» яңгырый...» – дип, ул көннәрдә бик популяр булган җырны куеп җибәргәнмен. Үзем дә аңламастан, Әлфис абый янына «озатканмын» радио тыңлаучыны. Шул мәлдә Салават абый түзмичә, машинасын туктатып, радиога шалтырата.

Аның: «Ризәлә, синең авызың нәрсә әйткәнне колагың ишетәме?» – дигәне, ә үземнең: «Әйтеп бетергәч кенә ишетә икән шул», – дигәнем хәтердә...

Менә шундый тарих.

Ә җырларга килгәндә, кайбер җырны шулкадәр яратасың, кайбервакыт мәгънәсен дә онытып җибәрәсең шул. Ә Салават абыйның җырларын гел ярата халык. Кызык хәлләр булгалады инде ул елларда. Шулай бервакыт ирем нинди җыр яратуымны сорады. Мин дә ике уйлап тормыйча гына, Салаватның «Сайрамаган сандугач» җыры, дигәнмен. Яңа чыккан вакыты булгандыр, күрәмсең. Мин барысын да радиодан үзем котлап өйрәнгәнгә, башыма да килмәде ирем миңа түләүле котлау бирер дип. Туган көндә: «Сюрприз! – ди бу. – 10 минуттан радиодан котлау була!» Мин инде тизрәк әнигә шалтыратам, тыңлагыз, янәсе. Котладылар... һәм җыр – «Сайрамаган сандугач»! Ирем-җаныем бер агарды, бер кызарды. «Яратмаган ярлар белән торсаң ни, тормасаң ни», – дип сибә генә Салават абый. Әни шалтырата (әллә елый да иде инде): «Нәрсә дигән сүз булды бу, кызым?» – ди... «Минем яраткан җырым бу, әни», – диюдән башка берни әйтә алмадым... Менә шундый хәлләр дә була артык яратудан...

Синең җырың халык өчен – чишмә,
Арган атка эчәр су кебек...
Лаек киңлек биргән Хак Тәгалә,
Агымың шифасын белеп.
Вак чуерташ синең өчен таулар,
Акыл белән яргач юлларың.
Татар халкы исән калсын өчен,
Һава кебек кирәк моңнарың!

Ризәлә ИСМӘГЫЙЛЕВА

Такта куярга кирәк!

Әле шушы көннәрдә генә бакыйлыкка күчкән Йосыф абый Закировны әйбәт беләидем. Пачулга баргач (безнең якта Йолдыз поселогын шулай атыйлар), өйләренә дә сугылып чыгарга туры килгәләде. Һәрчак ачык йөзле, шат күңелле, бик кунакчыл кеше иде ул. Беркайчан чәй эчермичә җибәрмәде. Дамирә апаның бәлешеннән авыз итәргә дә туры килде.

Йосыф абый кешегә ачу сакламады, эчендәгесе гел тышында булды. Дөрес, күңеле тулган чакларында бераз ярсыбрак китә торган гадәте барлыгын да хәтерлим. Әмма озакка түгел, шунда ук, кем әйтмешли, кире кайтып төшә иде. Берзаман үз хуҗалыгын күрсәтеп йөри бу миңа. Ишегалды зур, чиста, җирдә бер салам кисәге дә күрмәссең. Койма ярыгыннан гына бакчасына күз салдым. Ник бер чүп үлән булсын шунда! Йосыф абый лапасын да күрсәтеп чыкты. Сыер ята торган идәннең чисталыгын күреп таң калдым. Менә бит, дим, тырыш кешенең лапас идәне дә ялт итеп тора. Аннары мунча ишеген ачып җибәрде. Дөресен әйтим, моңарчы мондый мунчаны беркайда күргәнем булмады. Аның зурлыгын, иркенлеген белсәгез икән! Җигүле ат белән борылып чыгарлык. Эчендәге чисталык хастаханәнең процедура кабинетыннан һич ким түгел.

– Наным, бу мунчаның стенасына такта куярлык! – ди Йосыф абый.

Мин берни аңышмыйча аңа күтәрелеп карадым.

– Стенасы болай да тышланган бит...

– Истәлек тактасы, дип әйтмәкче идем, истәлек тактасы...

– Танылып, тарихта үзләреннән якты эз калдырган кешеләр яшәгән йортка гына куялар бит андый истәлек билгесен, Йосыф абый, – дим.

– Анысын дөрес әйтәсең инде дә, ну, малай, минем мунча да андый йорттан ким түгел! Заманында Яңа Рәҗәп мәктәбенең «Кече Артек» лагере гөрләп торды бит. Татарстанның бик күп районнарыннан килеп семинарлар, төрле фестиваль-конкурслар оештырып бетерделәр. Безнең якларның матур табигатен язучы-шагыйрьләр, җырчылар, сәнгать әһелләре дә үз итте. Казаннан берәр кунак-мазар киләсе булса, Әнвәр абыегыз гел кызу итеп мунча ягарга куша иде. Илһам Шакиров, Әлфия Авзалова, Гөлзада Сафиуллина, Габдулла Рәхимкулов, Фәннур Сафин, Җәүдәт Дәрзаман, Риф Гатауллин, Хәния Фәрхи, Гариф Ахунов, Марсель Галиев – санап бетерерлек түгел – барысын да мунча керттем. Мәтрүшкәле себерке белән чабынып туймадылар, аркадан чәбәкләп рәхмәт әйтәләр иде...

Ни кызганыч, югарыда телгә алынган җырчы, шагыйрь һәм язучыларның инде күбесе арабыздан китеп барды. Шулар белән кул биреп күрешүне һәм азмы-күпме булса да аралашуны Йосыф абый үзе өчен бәхеткә санады. Гариф Ахунов аңа рәхмәт йөзеннән култамгалы китабын да бүләк иткән әле.

Тәлгать ҖАМАЛЕТДИНОВ

ЧАМА ХИСЕ ЮГАЛСА...

Шөкер, бакчамда бәрәңге, җиләк-җимеш үстереп, күңелемә рәхәтлек алам, эштән бушаган араларда газета-журналлар, китап укыйм, радио тыңлыйм, телевидение тапшыруларын карыйм. Лаеклы ялдагы көнем һич кенә дә бушка үтми, гомерне заяга уздырмыйм.

Соңгы вакытта Гарриет Бичер-Стоуның «Том агай алачыгы»н хәтердә яңарттым, үзебезнең элеккеге рәвешебез белән чагыштырдым. Кешедән кол ясау, изү безнең илдә дә ерак йөрмәде. Мисалмы? Районыбыз хуҗалыкларының берсендә армый-талмый хезмәт итүче Ибраһим атлы кеше белән танышкан идем. Дуслашып киттек, хәл-әхвәл белешеп яшәдек һәм... көннәрдән бер көнне Ибраһим күренми башлады, хәбәрсез югалды.

Район үзәгендә эшем беткәч, мин, автобуска утырып, Нократ Аланы пристанена юл тоттым. Караңгы төшкән иде инде, шунда берәү: «Исәнме, Мансур», – дип, кул сузды. Мин аптырап калдым. «Әллә танымыйсың инде? – диде кул сузучы. – Бу мин – Ибраһим бит». Төсмерләдем, сорау да бирмичә булдыра алмадым: «Бәрәәч, нишләп матрос киеменнән соң син?» «Әйдә минем каютага керик, шунда сөйләрмен», – диде танышым.

– Соңгы вакытта миңа төп эшемнән тыш җәмәгать эшләре дә өя башлаганнар иде, – дип сөйләп китте Ибраһим. – Үзең беләсең инде: алар – бер тиенсезгә эшләнә торган эшләр. Дөресен әйткәндә, бик нык арыдым мин андый эшләрдән. Шәхси хуҗалыкны карарга да кул җитми башлады. Өйгә дә вакытында кайтып кергән булмады. Җәмәгать эшен өстеөстенә өя тордылар, җитмәсә, отчет сорап, теңкәгә тиделәр. Шуннан соң минем башта: «Эштән китимме икән әллә?» – дигән уй бөреләнде һәм шул уй җиңеп тә чыкты. Әмма без бит эшсез торырга күнекмәгән, менә хәзер шушы вазыйфада, җәмәгать эше белән интектермиләр, хезмәт хакын вакытында түләп баралар.

Танышымны тыныч кына тыңлый торгач, әллә минем турында сөйли инде, дигән уй да килде. Әйе, төп хезмәтендә җигелеп эшләүчеләргә өсте-өстенә җәмәгать эше өеп, төп хезмәттән биздергән вакытлар да бар иде шул. Алары да кирәк булгандыр инде, әмма артыкка китсә, чама югалса, чын-чынлап артык була иде шул.

Мансур ХӘСӘНОВ

Менә нинди тамаша!

Иртә белән тәмләп кенә
Чәйләп утыра идек:
Кәрниздән бер кара нәрсә
Килеп төште шап итеп.

Баштан тычканга охшаттык,
Аннан канатлар җәйде.
Кәрниздә йоклап чыккандыр
Шулай иртәнгә хәтле.

Рәзилә белән карашып,
Калдык без аптырашта.
Мондый нәрсә күргән дә юк,
Менә нинди тамаша!

Кереп киттем күршеләргә,
Барын аңлатып бирдем.
Курыкмыйча коткарсын дип,
Пирчәткә дә кидердем.

Тиз генә өйгә кереп, ул
Күреп алды кошкайны.
Канатыннан тотып алып,
Форточкадан чыгарды.

Ярканат булган икән ул,
Белмәгәнбез без генә.
Куркуларыбыз басылды,
Күп вакыт үткәч кенә.

Ярый әле күршеләр бар,
Булышырга, якларга.
Бер-беребезне аңлыйбыз
Шундый авыр чакларда.

Әлфия ШӘФИГУЛЛИНА.
Казан

БЕЗНЕ «ХЕЗМӘТ» КҮТӘРДЕ!

Балтач районында нәшер ителүче «Хезмәт» газетасы турында әйтүем. Газетаның нәшер ителә башлавына быел 90 ел. Шушы газетада 56 ел элек миңа хәерхаһлы булганнары өчен журналистларга һәм, әлбәттә инде, бүгенге иҗади коллективка олы рәхмәтлемен.

Без – бер төркем мәктәп укучылары яшь хәбәрчеләр булып киттек һәм «Хезмәт»тә язмаларыбыз басылу укуга да, яшәешебезгә дә дәрт бирде. «Хезмәт» дәртләндереп торгач, Салавыч мәктәбендә укытучыларыбыз нияте белән яшь хәбәрчеләр түгәрәге дә оештырылган иде. Минем гаилә архивында 1966 елда төшерелгән истәлекле фото да саклана. Шул фотоны сезнең игътибарга да тәкъдим итәм. Анда яшь хәбәрчеләр түгәрәгенә йөрүчеләр чагылыш таба. Мин үзем түгәрәкнең җитәкчесе идем. Рәйхан Кәлимуллин, Икрам Мөбарәкшин, Рәис Зыятдинов, Зөлфия Абдуллина, Фирая Фазылҗанова, Миләүшә Фатыйхова, Дания Мөхлисова, Гөлнур Минһаҗева, Гәүһәр Галиева түгәрәккә бик теләп йөрделәр. Өлкән пионервожатый Җәмилә апа Сабирова безне илһамландырып торды. 5–6 нчы сыйныфларда укыганда татар теле укытучыбыз Әминә апа Фазылҗанова безгә шигырьләр яздыра башлады. Шул шигырьләремне кулыма тотып, редакция баскычыннан күтәрелүем дә бүгенгедәй хәтеремдә. Мине Риф абый Якупов янына керттеләр. Үз тиңедәй күреп, минем белән кул биреп күреште, хыял-теләкләрем белән кызыксынды, редакциягә юлны онытма, дип киңәш бирде. Тора-бара белүемчә, үзе гел эзләнүдә, фәнни эшләр белән шөгыльләнүдә иде. Тукайның тормышын, иҗатын өйрәнеп, аны дөньяга китергән Мәмдүдә абыстайның кабере Сасна Пүчинкәсендә булуын да беренче тапкыр аның ачыклавы мәгълүм.

Сигезьеллык мәктәпне тәмамлап, колхозда эшли башлагач та хәбәрчелек эшчәнлегемне туктатмадым. Ул чорда эшләгән журналистлар Мәгъсүм Хуҗин, Дифкать Сираев, Риф Якупов, Рәфыйк Шәрәфиев, Фәридә Шакирова, Мидхәт Гыйрфанов, Харис Әшрәфҗанов, Нәфыйк Шәфигуллин, Әхәт Фазылҗановтан һ.б. хәбәрләремә рәхмәт сүзләре әйтелгән, уңышлар теләгән хатлар килә иде.

Остазларымның җылы сүзләре үсендереп торды. Ел саен район хәбәрчеләре киңәшмәләрендә катнашып, бүләкләргә дә лаек булдык.

Хәзер дә «Хезмәт» – күңел күгебездәге якты кояшыбыз ул. Гомумән, матбугатның көче-кодрәте бәхәссез, татар укымыйча, илаһамланмыйча яши алмый ул. Тик газета-журналларның тиражы кимү генә күңелне тырный. Әмма бу вакытлыча күренеш булыр, дип беләм.

Рамазан ФӘРЗИЕВ

Шарик белән Йомры дуслыгы

Үзара талашып яшәүче кешеләр турында, гадәттә, эт белән мәче кебек яшиләр, диләр. Мин бу сүзләр белән килешмим.

Безнең кечкенә көчегебез бар. Көз башланган иде инде. Ишегалдыбызга кайдандыр йомры гына (мин аны Йомры дип атадым) бер песи баласы килеп керде. Көз көне безнең ишегалдында күбәяләр алар. Ник дигәндә, авылыбызга ерак түгел дачалар урнашкан, дача сезоны тәмамлангач, кайберәүләр шушы дүрт аяклы «дус»ларын язмыш иркенә калдырып кайтып китәләр. Билгеле инде, хайваннар шул тирәдәге авылларга – тормыш элеккечә дәвам иткән йортларга ияләшәләр.

Безнең көчегебез Шарик көне буе чаба, сикерә, безгә иркәләнә. Минем иртән торып чыкканымны түземсезлек белән көтеп ала ул. Әмма беркөнне мин аны күрмәдем. Эзли башладым. Күрәм: бакчада ике йомгак тәгәрәшә. Игътибар беләнрәк карагач, Шарикны танып алдым. Ул, рәхәтләнеп, Йомры белән уйный иде. Бер-берсен куалар, тәгәриләр, авырттырмый гына тешләшкән булалар. Аларга гына түгел, миңа да кызык тоелды бу күренеш. Шарик белән Йомрының дуслыгы көннән-көн ныгыды. Алар хәзер бер-берләреннән башка тора алмыйлар иде. Көн буе чабалар, күбәләкләр куалар, ашыйлар. Мин тагын шунысына игътибар иттем: безнең Шарик чын егет тә икән бит. Ул сакта торып, башта Йомрыны ашата, аннары гына үзе «табын» янына килә. Сөякләр булса, аңа шул җитә, сөтне Йомрыга бирә.

Кечкенәләрнең дуслыгы, кышкы салкыннар башлангач, аеруча ныгыды. Шарикка әтием каяндыр бик шәп бер оя алып кайтып куйды. Бу оягa этем үзенең дустын да чакырды. Салкын көннәрдә алар икесе бергә шул ояга кереп яталар. Шарик ишек турысына ята һәм шул рәвешле үзенең дустын ачы җилләрдән, зәмһәрир суыклардан саклый. Йомры исә дустына сыенып йокларга ярата. Аларның дуслыкларына хәйран калып, сокланып туймыйм.

Н.ГЫЙМАДИЕВА

«БӘЛЛҮР КАЛӘМ» БӘЙГЕСЕНЕҢ II ТУРЫНА УЗУЧЫЛАР

Журналистика һәм массмедиа өлкәсендә «Бәллүр каләм» – «Хрустальное перо» XXV республика конкурсының икенче турына үткән катнашучылар исемлеге билгеле булды.

«Журналистикага тугрылык өчен» номинациясе
1. Равил Ибраһимов («Честное слово» газетасы)
2. Әскәр Сабиров («Татарстан» журналы)
3. Әлфия Мөхәмәтова («Актаныш» радиосы)
4. Ирек Нигъмәтҗанов («Гаилә һәм мәктәп» журналы)
5. Инсаф Абдуллин («Яңа Гасыр» ТРК)

«Мультимедияле редакция» номинациясе
1. «Норлат-информ» мәгълүмат үзәге
2. «Ялкын» журналы редакциясе
3. «Яңа Гасыр» ТРК (интернет-редакция)
4. «Татарстан» ДТРК (яңалык программалары хезмәте)
5. «Авыл утлары» газетасы редакциясе (Мөслим)
6. «TATARSTAN NEWS»

«Иң яхшы район (шәһәр) редакциясе» номинациясе
1. «Нижнекамская правда» газетасы редакциясе
2. «Казань» журналы редакциясе
3. «Авыл утлары» газетасы редакциясе (Мөслим)
4. «Тәртип» радиосы редакциясе
5. «Хезмәт» газетасы редакциясе (Балтач)
6. «Казан утлары» журналы редакциясе

«Һөнәрдә иң яхшысы» номинациясе
1. Михаил Любимов («Яңа Гасыр» ТРК)
2. Ольга Степанова («Челнинские известия» газетасы)
3. Гөлнар Гарифуллина («Татар-информ» – «Интертат»)
4. Гөлназ Шәйхиева («Татарлар» газетасы)
5. Зилә Фәйзуллина («Сабантуй», «Салават күпере» журналлары)
6. Римма Афзалова («Авыл утлары» газетасы, Мөслим)
7. Дилбәр Гарифуллина («Шәһри Казан» газетасы)

«Ел фоторепортеры» номинациясе
1. Анна Арахамия («Сөембикә» журналы)
2. Идрис Әхмәтов («Сельские горизонты» газетасы, Балык Бистәсе)

«Ел телеоператоры» номинациясе
1. Евгений Лызаев («Нижнекамск-информ» МУ)
2. Андрей Корсинский («Яңа Гасыр» ТРК)

«Нәтиҗәле матбугат хезмәте» номинациясе
1. Нижнекамск муниципаль районының матбугат хезмәте
2. ТНГ-Групп матбугат хезмәте (Бөгелмә)

«Популяр блогер» номинациясе
1. «ШАЯН ТВ» телеканалы
2. Фагыйлә Шакирова

«Туган тел» номинациясе
1. «Яңа Гасыр» ТРК корреспондент пункты (Магнитогорск шәһәре)
2. «Яңарыш» газетасы (Удмуртия Республикасы)

«Татарстан Республикасында туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын иң яхшы яктырту» номинациясе
1. «Новый Зай» газетасы
2. «Нижнекамская правда» газетасы
3. «Хозур» нәшрият йорты
4. «Актаныш-информ» мәгълүмат үзәге
5. «Татарстан» ДТРК
6. «Ватаным Татарстан» газетасы
7. «Татарстан» журналы

«Россия Федерациясендә фән һәм технология елын иң яхшы яктырту» номинациясе
1. «Геофизик Татарии» газетасы (Бөгелмә)
2. Алена Демина («Татарстан-24»)
3. Олеся Бондаревская («Татарстан» журналы)
4. «Идел» журналы
5. Раил Садретдинов («Татарстан» ДТРК)

«Татарстан Республикасында милли проектларны яктырту буенча иң яхшы ММЧ редакциясе»
1. «Зай-ТВ» телекомпаниясе
2. «Нократ»/«Вятка» газетасы (Мамадыш)
3. «Чистопольские известия» газетасы
4. «Яңа Гасыр» ТРК мәгълүмати тапшырулар дирекциясе
5. «Сарман» газетасы

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ КАРАРЫ

гражданка Г.Ж. Галимжанова шикаятенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1132 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү чиратын билгеләү критерийларын файдалану тәртибенә кушымтаның 3.2 пунктының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 30 сентябрендәге 739 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау зарурлыгын билгеләү тәртибенең 1.2, 3.1 һәм 3.7 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләренең конституциячелеген тикшерү турындагы эш буенча

Казан шәһәре 2022 елның 28 июне

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы беренче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1132 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү чиратын билгеләү критерийларын файдалану тәртибенә кушымтаның 3.2 пунктының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 30 сентябрендәге 739 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау зарурлыгын билгеләү тәртибенең 1.2, 3.1 һәм 3.7 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләренең конституциячелеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка Г.Ж. Галимжанованың шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган нормативның хокукый нигезләмәләренең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья М.М. Хәйруллин мәгълүматын, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы юридик бүлегенең әйдап баручы киңәшчесе Ф.М. Мөхәммәдиева аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

билгеләде:

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Г.Ж. Галимжанова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1132 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү чиратын билгеләү критерийларын файдалану тәртибенә кушымтаның (алга таба шулай ук – 1132 номерлы тәртипкә кушымта) 3.2 пункты белән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 30 сентябрендәге 739 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау зарурлыгын билгеләү тәртибенең (алга таба шулай ук – 739 номерлы тәртип) 1.2, 3.1 һәм 3.7 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре белән үзенең конституциячел хокукларын һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

1132 номерлы тәртипкә кушымтаның 3.2 пункты күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү чиратын билгеләү критерийларының күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертемнәр түләүнең түләү дисциплинасы (исәпләүләргә карата түләү проценты) кебек шундый критерием бәяләнүе билгеле.

739 номерлы тәртипнең 1.2 пунктында аның Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның кирәклеге (зарурлыгы булмау) турында карарлар кабул итү максатларында, Россия Федерациясе Торак кодексының 181 статьясындагы 5 өлешендә һәм 189 статьясындагы 7 өлешендә каралган очракларда, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча аерым төр хезмәт күрсәтүләрне һәм (яисә) эшләрне күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программага кертү, кертмәү яисә төшереп калдыру турындагы мәсьәлә, шулай ук региональ программада каралган хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең срогын иртәрәк чорга күчерү турындагы мәсьәлә каралган очракта кулланылуы күз алдында тотыла.

Шул ук Тәртипнең 3.1 пунктында ачыкланганча, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның кирәклеген (кирәк булмавын) билгеләү өчен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар, күпфатирлы йорт белән идарә итүче гамәлгә ашыручы оешмалар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) түбәндәге документларны кушып, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген (кирәк булмавын) билгеләү турында вәкаләтле органга гариза (алга таба – гариза) тапшыралар:

– гражданнарның яисә башка кызыксынган затларның күпфатирлы йортта яшәү шартлары канәгатьләнмәслек булуы турында мөрәҗәгате – мөрәҗәгать итүче карары буенча;

– Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Техник инвентаризация бюросы» республика дәүләт унитар предприятиесенең күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтнең торышы турында бәяләмәсе;

– күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның кирәклеген (кирәк булмавын) билгеләү турында күпфатирлы йортта урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары беркетмәсе (Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы 4 өлешенең 1–3 пунктларында каралган очракларда тапшырылмый).

739 номерлы тәртипнең шикаять белдерелә торган 3.7 пункты нигезендә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген билгеләү буенча комиссия (алга таба шулай ук – комиссия) әлеге Тәртипнең 3.6 пунктында күрсәтелгән документларны алган көннән алып 20 эш көненнән дә соңга калмыйча расланган һәм түбәндәге нәтиҗәләрнең берсен расланган көннән алып өч эш көне эчендә вәкаләтле органга тапшыра:

– күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеге турында. Күрсәтелгән карарны кабул итү нигезләре түбәндәгеләр була: күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә чираттагы капиталь ремонт (норматив-ремонтара сроклар) уздырганчы кадәр конструктив элементлар һәм инженерлык системалары хезмәтенең норматив срокларын арттыру; күпфатирлы йортның конструктив элементларының ышанычлылыгының һәм иминлегенең билгеләнгән чик характеристикаларын бозу куркынычы булу (3.7.1 пункт);

– күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәк булмавы турында. Күрсәтелгән карарны кабул итү нигезләре түбәндәгеләр була: күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә чираттагы капиталь ремонт (норматив-ремонтара сроклар) уздырганчы кадәр конструктив элементлар һәм инженерлык системалары хезмәтенең норматив срокларын арттырмау; күпфатирлы йортның конструктив элементларының ышанычлылыгының һәм иминлегенең билгеләнгән чик характеристикаларын бозу куркынычы булмау (3.7.2 пункт).

Шикаятькә һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Г.Ж. Галимжанова күпфатирлы йортта яши. 2016 елда әлеге йортта өлешчә капиталь ремонт үткәрелгән. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программа нигезендә туры капиталь ремонт үткәрү 2043 елга планлаштырылган. Әлеге йортның тузуын һәм аны файдалануга тапшыру елын исәпкә алып, мөрәҗәгать итүче аңа капиталь ремонт үткәрү датасын иртәрәк чорга күчерү өчен нигезләр бар дип саный. Әмма, аның расламы буенча, 739 номерлы тәртипнең шикаять белдерелә торган 1.2, 3.1 һәм 3.7 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре фактта күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү срогын иртәрәк чорга күчерергә мөмкинлек бирми, чөнки мондый мәсьәләне карау мөмкинлеген күздә тотып, тиешле процедураны беркетмиләр. Аерым алганда, ул әлеге нормаларда аталган мәсьәләне карау өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар, шулай ук аны карау нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларның нигезләре һәм төрләре билгеләнмәгән дип күрсәтә. Шулай итеп, ул әлеге үзара бәйле нигезләмәләр хокукый билгеләнешнең конституциячел принцибын боза һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә дип саный.

Мөрәҗәгать итүче билгеләп үткәнчә, 1132 номерлы тәртипкә кушымтаның 3.2 пункты, күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү чиратын билгеләүнең күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертемнәр түләүнең түләү дисциплинасы кебек критериен бәяләүне билгеләп, әлеге түләү дисциплинасын исәпләнә торган чорны билгеләми, шуңа бәйле рәвештә дәгъва белдерелә торган норма, аның фикеренчә, аңлаешсыз һәм билгесез булудан, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Г.Ж. Галимжанова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1132 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү чиратын билгеләү критерийларын файдалану тәртибенә кушымтаның 3.2 пунктын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 30 сентябрендәге 739 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау зарурлыгын билгеләү тәртибенең 1.2, 3.1 һәм 3.7 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 17 (икенче өлеш), 18 (беренче өлеш), 19 (беренче өлеш), 28 (беренче өлеш) һәм 51 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре – иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау – Татарстан Республикасының бурычы; икътисади мөнәсәбәтләр граждан белән дәүләт, кулланучы белән җитештерүче, эшләүче белән эш бирүче арасындагы социаль партнерлыкка корыла; Татарстан Республикасында хосусый, дәүләти, муниципаль милек һәм милекнең башка рәвешләре бертигез дәрәҗәдә таныпла һәм яклана; милек кагылгысыз; законлы рәвештә булдырган милектән һәм милекнең башка рәвешләре бертигез дәрәҗәдә таныпла һәм яклана; милек кагылгысыз; законлы рәвештә булдырган милекне бербер хар, законда каралган очраклардан гайре, рөхсәт ителми; закон һәм суд каршында һәркем тигез; Татарстан Республикасы кулланучы мәнфәгатьләрен яклый һәм аның хокукларын яклау буенча иҗтимагый эшчәнлекне хуплый; кулланучылар товар җитештерүчеләрнең, хезмәт күрсәтүчеләрнең китергән зыянын законда билгеләнгән тәртиптә түләттерергә хокуклы.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә бүтән органнар компетенциясенә кергән барлык очракларда фактларны хәлләрне ачыкладан һәм тикшерүдән тыелып кала.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячелеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча түбәндәгеләр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора:

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1132 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү чиратын билгеләү критерийларын файдалану тәртибенә кушымтаның 3.2 пункты, чөнки ул, Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү чиратын билгеләү критерие буларак, күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнәр түләүнең түләү дисциплинасын бәяләү өчен норматив нигез булып торганга күрә;

– Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 30 сентябрендәге 739 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау зарурлыгын билгеләү тәртибенең 1.2, 3.1 һәм 3.7 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре, алар тарафыннан беркетелгән хокукый җайга салу кысаларында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программада билгеләнгән срокларга карата капиталь ремонт үткәрү срогын иртәрәк чорга күчерү хокукын гамәлгә ашыру мөмкинлеге билгеләнгән дәрәҗәдә.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нормалар торак законнары өлкәсенә кагыла, алар Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлеш, «к» пункты) нигезендә Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы (2 һәм 5 өлешләр) буенча Россия Федерациясе субъектларының әлеге өлкәдәге законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнар нигезендә кабул ителә һәм аларга каршы килә алмый.

Нигезләмәсенә карата гражданка Г.Ж. Галимжанова шикаять белдерә торган 2013 елның 31 декабрендәге 1132 номерлы карарның кабул итү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә кагылышлы мәсьәлә элек Татарстан Республикасы Конституция судының тикшерү предметы булган иде, ул, карала торган норматив хокукый актны кабул итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Конституциясендә, шулай ук федераль һәм республика законнарында каралган үз вәкаләтләре чикләрендә эш итте дигән нәтиҗәгә килде (2019 елның 18 октябрендәге 85-П номерлы карар). Татарстан Республикасы Конституция судының күрсәтелгән карары һәм анда чагылдырылган хокукый позициясе үз көчләрен саклый.

Россия Федерациясе Торак кодексының 5 статьясындагы 6 өлешенең һәм 13 статьясындагы 8.3 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре буенча Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү кирәклеген ачыклау тәртибен билгеләүгә юнәлдерелгән нормаларны үз энчә алган законнар һәм башка норматив хокукый актлар кабул итә.

Федераль законның күрсәтелгән нигезләмәләрен үстереп, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июньдәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба шулай ук – 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) кабул ителгән, аның нигезендә мондый тәртипне билгеләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә кертелгән (3 статьяның 1 өлешендәге 13.1 пункты).

Димәк, карала торган «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау зарурлыгын билгеләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 30 сентябрендәге 739 номерлы карарны кабул итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенә федераль һәм республика законнары нигезендә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең үзара бәйле 102 (1 пункт) һәм 103 статьялары нигезләмәләреннән таянган вәкаләте законлы рәвештә гамәлгә ашырган, алар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз вәкаләтләре чикләрендә кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру, тәэмин итү һәм яклау чараларын күрә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара, аларның үтәлешен тикшерә.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасын социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), һәркем торакка хокуклы, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар (55 статья), дип беркетә. Мәгънәсе буенча охшаш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясендә, шул исәптән аның 7 (1 өлеш) һәм 40 (1 һәм 2 өлешләр) статьяларында билгеләнгән.

Россия Федерациясе Конституция Суды үзенең 2016 елның 12 апрелендәге 10-П номерлы Карарында күрсәткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә Россия, сәясәте кешегә лаеклы тормыш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлдерелгән социаль дәүләт буларак (7 статья, 1 өлеш), һәркемнең торакка хокукын гамәлгә ашыруны гарантияли (40 статья, 1 өлеш); шуннан чыгып, Россия Федерациясе Конституциясе, һәркемнең торакка хокукын игълан итеп, әлеге хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру буенча дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының үзара бәйләнешле булу бурычын беркетә (40 статья, 2 өлеш), бер үк вакытта аны гамәлгә ашыру гарантиясе булып тора; торак мөнәсәбәтләрен хокукый җайга салуның нигезен тәшкил итүче әлеге конституциячел күрсәтмә дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына караган Россия Федерациясе территориясендә урнашкан һәм торак хокуклары объектлары булып торучы барлык торак урыннар җыелмасын тәшкил итүче торак фондының сакланышын тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган шундый хокукый механизмнары билгеләү турындагы таләпне аңлата (Россия Федерациясе Торак кодексының 15 статьясындагы 1 өлеше һәм 19 статьясындагы 1 өлеше) һәм кешенең төп ихтыяҗларының берсе – торакка булган ихтыяҗны тормышка ашыру, бу, үз чиратында, торак фонды объектларының максатчан билгеләнешен саклануны, шулай ук аларда гражданнарга яшәү өчен имин һәм уңайлы шартлар тудыруны күздә тота; торак урыннарның торак фондын тәшкил итүче күпчелек өлеше урнашкан күпфатирлы йортлар табигый тузуга дучар ителгән, шуңа күрә мондый йортларны тиешле тәртиптә тоту шул исәптән аларның техник торышына өзлексез мониторинг үткәрүне, шулай ук аларның конструктив элементларының позексезлекләрен бетерү буенча кирәкле эшләрне вакытында башкаруны да күздә тота.

3.1. Россия Федерациясе Торак кодексы Россия Федерациясе Конституциясенең 40 статьясын (2 өлеш) конкретлаштыру тәртибендә дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына торак фондын файдалануны һәм аларның сакланышын тикшерен торуны тәэмин итү, күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә мондый йортларда торак милекчеләренең кертемнәре исәбеннән, бюджет акчалары һәм законда тыелмаган башка финанслау чыганаклары хисабына үз вакытында капиталь ремонт үткәрүне оештыру, шулай ук дәүләт торак күзәтчелеген һәм муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча бурычлар йөкли (2 статьяның 6, 6.1 һәм 8 пунктлары).

Әлеге бурычларны тормышка ашыру күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне оештыру тәртибен, аерым алганда, күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программаларны (алга таба шулай ук – капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программа) әзерләү һәм раслау процедурасын регламентлауны да кертеп, хокукый җайга салуны билгеләүне күздә тота.

Күрсәтелгән Кодексның 168 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләре нигезендә күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауның региональ программасы Россия Федерациясе субъектының иң югары дәүләт хакимияте башкарма органы тарафыннан раслана, шул исәптән күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауны планлаштыру һәм оештыру, мондый йортларда торак милекчеләре, региональ оператор тарафыннан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауның үз вакытында башкарылуын тикшереп тору максатларында да; Россия Федерациясе субъекты территориясендә урнашкан барлык күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауга кирәкле булган срокка формалаштырыла; авария хәлендә дип танылган һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле күпфатирлы йортлардан тыш, Россия Федерациясе субъекты территориясендә урнашкан барлык күпфатирлы йортлар исемлеген үз эченә ала. Шул ук вакытта күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау чираты күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауның региональ программасын раслаучы Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән һәм муниципаль берәмлекләр буенча дифференциацияләнергә мөмкин булган критерийлардан чыгып билгеләнә (Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы 3 өлеше).

Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны үз вакытында үткәрү, шулай ук мондый капиталь ремонт үткәрүне оештыру мәсьәләләре 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән җайга салынган, аның 11 статьясында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгын билгеләү критерийлары, шул исәптән капиталь ремонтны финанслауда урыннар милекчеләренең өлешен белдерә торган финанс критерие билгеләнгән (3 өлешнең 3 пункты). Күрсәтелгән статьяның 4 өлешен үтәп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карала торган 1132 номерлы тәртипкә кушымтада күрсәтелгән финанс критериен кулланунын шундый тәртибен ачыклаган, анда күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертем күләме (3.1 пункт) һәм күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертемнәр түләүнең түләү дисциплинасы (исәпләүләргә карата түләү проценты) (3.2 пункт) балл системасы буенча бәяләнергә тиеш.

Финанс критериен билгеләү Россия Федерациясе Торак кодексының 169 һәм 170 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә нигезләнгән, аларда күпфатирлы йортта торак милекчеләренең күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга ай саен кертемнәр түләү һәм, нәтиҗә буларак, күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау фондын формалаштыруда катнашу бурычын беркетә.

Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, гамәлдәге хокукый җайга салу системасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнәр мондый йортлардагы торак милекчеләренең мәҗбүри түләүләре формаль юридик мәгънәдә була, алар, тиешле мөнәсәбәтләрнең гавами әһәмияткә ия булуы нигезендә, Россия Федерациясе Торак кодексы тарафыннан күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне оештыру һәм үткәрүне финанс белән тәэмин итү максатларында, аларны санитар һәм техник таләпләргә туры килә торган хәлдә тоту өчен каралган, шуның белән әлеге взносларның фактта индивидуаль ихтыяри характеры тәэмин ителә (2016 елның 12 апрелендәге 10-П номерлы Карар).

1132 номерлы тәртипкә кушымтаның дәгъва белдерелә торган 3.2 пунктында каралган күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү чиратын билгеләү критерием – күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертемнәр түләүнең түләү дисциплинасын анализлау күрсәткәнчә, аны кертү торак милекчеләренең тиешле күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотарга бурычлы булуы белән алдан билгеләнгән (Россия Федерациясе Торак кодексының 30 статьясындагы 3 өлеше). Дәгъва белдерелә торган норма нигезендә күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертемнәр түләүнең түләү дисциплинасы күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертемнәр исәпләүгә карата түләү проценты буларак билгеләнә, аны исәпләү нәтиҗәләре буенча 0 дән 10га кадәр тиешле баллар бирелә. Дәгъва белдерелә торган норманың сүзгә-сүз эчтәлегеннән чыгып, аның 1132 номерлы тәртипкә кушымтаның 3 пункты белән бәйләнешендә, анда билгеләнгән җайга салу 2015 елдан бирле кулланыла. Шикаять белдерелә торган норманың максатчан билгеләнеше – финанс критериен куллану тәртибен конкретлаштыру, атап әйткәндә, күпфатирлы йортта торак милекчеләренең капиталь ремонт үткәрүне финанслауда катнашуын бәяләү процедурасын билгеләү.

Шулай итеп, Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү чиратын билгеләү критерие буларак, күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертемнәр түләүнең түләү дисциплинасын беркетүче 1132 номерлы тәртипкә кушымтаның 3.2 пункты үзеннән-үзе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан аның дискрецион вәкаләтләре чикләрендә кертелгән, торак милекчеләренең җаваплылык дәрәҗәсен һәм хокукый аңын арттыруга юнәлдерелгән һәм гамәлдәге хокукый җайга салу системасында үзенең эчтәлегеннән һәм урыныннан чыгып, Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә дип таныла алмый.

Шуның белән бергә, күпфатирлы йортта торак милекчеләренең капиталь ремонт үткәрүне финанслауда катнашуын бәяләү процедурасын билгеләүдән гыйбарәт булган 1132 номерлы тәртипкә кушымтаның 3.2 пунктының югарыда аталган максатчан билгеләнешен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды шикаять белдерелә торган норманы Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану карала торган хокукый җайга салуны камилләштерүгә каршылык тудырмый дип саный. Дәгъва белдерелә торган нигезләмәне бертөрле куллану максатларында Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, шул исәптән гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнәр түләүнең түләү дисциплинасын үтәүне бәяләү каралган чорны карала торган нормада чагылдырып, капиталь ремонт үткәрү чиратлылыгын билгеләүнең финанс критериен куллану процедурасын тулырак регламентлауга юнәлдерелгән төгәллекләр кертүне максатка ярашлы дип саный. Мондый үзгәрешләр 1132 номерлы тәртипкә кушымтаның 3.2 пунктын ирекле куллануга юл калдырмас иде һәм бу мәсьәләдә мөнәсәбәтләрне җайга салуның билгеләнеше, ачыклыгы һәм бер мәгънәдә булуына ярдәм итәр иде.

3.2. Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы 5 өлеше нигезендә капиталь ремонтның региональ программасы кимендә елга бер тапкыр актуальләштерелергә тиеш. Шуның белән бергә Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы, 170 статьясындагы 4.1 өлешенең хокукый күрсәтмәләре капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программага күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүнең билгеләнгән срогын соңрак чорга күчерүне, шулай ук капиталь ремонт үткәрүне күпфатирлы йорттагы торак милекчеләренең гомуми җыелышы карары буенча капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программада билгеләнгәнгә караганда иртәрәк срокларда үткәрүне күздә тоткан үзгәрешләр кертү мөмкинлеген билгели. Шуның белән капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программа капиталь ремонт үткәрү срокларын, аерым алганда, иртәрәк срокка үзгәртү мөмкинлеген дә һәм күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү буенча хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең планлаштырылган төрләрен төгәлләштерү һәм аны (ким дигәндә елга бер тапкыр) актуальләштерү юлы белән капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программага тиешле үзгәрешләр (өстәмәләр) кертү мөмкинлеген кире какмый торган сыгылмалы хокукый механизм һәм (яки) хокукый ориентирдан гыйбарәт.

Россия Федерациясе Торак кодексы торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә, башкалар белән берррәттән, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү кирәклеген ачыклау тәртибен билгеләүне дә кертә (13 статьяның 8.3 пункты). Әлеге җайга салу кысаларында һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеген күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү кирәклеген ачыклау тәртибен билгеләүне методик яктан тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2014 елның 4 августындагы 427/пр номерлы боерыгы нигезендә Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау кирәклеген билгеләү буенча методик тәкъдимнәр расланган. Югарыда күрсәтелгән методик тәкъдимнәрнең 7 пунктындагы 3 пунктчасы нигезендә тиешле тәртипкә, аерым алганда, комиссия яисә вәкаләтле орган тарафыннан капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программада билгеләнгән срокларга караганда иртәрәк (соңрак) капиталь ремонт үткәрү кирәклеге турында карар кабул иткәндә, капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программага үзгәрешләр кертү процедурасын регламентлаучы нигезләмәләр кертергә тәкъдим ителә.

Федераль законнарның китерелгән нормалары 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрендә тулысынча үз чагылышын тапкан, аның 10 статьясындагы 9 өлешендә Россия Федерациясе Торак кодексының югарыда күрсәтелгән нормасына охшаш рәвештә капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программа кимендә елга бер тапкыр актуальләштерелергә тиеш дип каралган. Күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау мәсьәләләре буенча вәкаләтләре беркетелгән, алар исәбенә күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеген ачыклау тәртибен билгеләү керә (13.1 пункт). Югарыда аталган закон нигезләмәләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан дәгъва белдерелә торган Тәртип кабул ителгән, аның хокукый җайга салу предметы булып Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның кирәклеген (кирәк булмавын) ачыклау процедурасы билгеләнгән (1.1 пункт). 739 номерлы тәртипнең 1.2 пункты нигезендә ул Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның кирәклеге (зарурлыгы булмау) турында вәкаләтле орган тарафыннан карарлар кабул итү максатларында кулланыла, Россия Федерациясе Торак кодексының 181 статьясындагы 5 өлешендә һәм 189 статьясындагы 7 өлешендә каралган очракларда, күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча аерым төр хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программага кертү, кертмәү яисә төшереп калдыру турындагы мәсьәлә, шулай ук региональ программада каралган хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең срогын иртәрәк чорга күчерү турындагы мәсьәлә каралган очракта кулланыла.

Үзенең хокукый асылы буенча 739 номерлы тәртипнең 1.2 пункты торак фонды объектларының максатчан билгеләнешен саклауга һәм аларда гражданнарның яшәве өчен куркынычсыз һәм уңайлы шартлар булдыруга юнәлдерелгән. Капиталь ремонт буенча хезмәт күрсәтүләрне һәм (яисә) эшләрне капиталь ремонтлау буенча региональ программада билгеләнгән срокларга караганда иртәрәк срокка күчерү мөмкинлеген тәэмин итү күпфатирлы йортларда гражданнарның имин яшәү шартларына хокукларын гамәлгә ашыру гарантияләренең берсе булып тора. Бу мәсьәлә капиталь ремонт үткәрү кирәклеген билгеләү мәсьәләсе белән, ягъни бинаны ремонтлауда кирәк булганда конструктив элементларны һәм инженерлык җиһазлары системаларын алмаштырып, аның ресурсын торгызу, шул исәптән гражданнарның тормышына һәм сәламәтлегенә, гомуми мөлкәткә һәм милекчеләрнең мөлкәтенә куркыныч янауларны булдырмау, шулай ук эксплуатацияләү күрсәткечләрен яхшырту максатларыннан чыгып, уртак охшашлыкка ия. Бу капиталь ремонт үткәрүне капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программада каралган срокларына караганда иртәрәк срокка күчерү кирәклеге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре белән, йортка капиталь ремонт үткәрү кирәклеген билгеләгәндә һәм аны капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программага керткәндә кулланыла торган шул ук төзелеш һәм оештыру-техник чаралар комплексы белән беркетелгән шул ук параметрлар системасы кысаларында билгеләнә дигәнне аңлата. Асылда, капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программада каралган хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең срогын иртә чорга күчерү турындагы карар дигәндә капиталь ремонт үткәрү кирәклеген билгеләү дә, ә аннары аны капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программада билгеләнгән срокларга карата иртәрәк срокларда уздыру турында карар кабул итү дә күздә тотыла. Үз чиратында, моның белән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның кирәклеген (кирәк булмавын) билгеләү процедурасын регламентлаучы карала торган Тәртипнең 2–4 бүлекләрен бәян итүнең логик эзлеклелеге дәлилләнгән, кулланылган формулировкалар, шул исәптән дәгъва белдерелә торган нормаларда да, универсаль мәгънәгә ия, шуңа күрә аларны куллану күчерү мәсьәләсенә дә кагыла.

Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау кирәклеге (кирәк булмавы) турында карар әзерләү өчен вәкаләтле орган комиссия төзи һәм аның составын раслый (1.3 пункт). 739 номерлы тәртипнең 2 бүлеге нигезләмәләре белән әлеге комиссияне формалаштыру процедурасы, шулай ук аның эшчәнлеге тәртибе беркетелгән.

Шул ук Тәртипнең дәгъва белдерелә торган 3.1 пункты белән күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның кирәклеген (кирәк булмавын) билгеләү турында вәкаләтле органга гариза бирү нигезләре һәм мондый инициативаны кертергә вәкаләтле затлар даирәсе ачыкланган. Шул ук вакытта 739 номерлы тәртип белән гражданнарның мондый гаризага күпфатирлы йортта яшәү шартларының канәгатьләнмәслек булуын таныклаучы документларны һәм (яки) башка материалларны кушымта итеп бирү өлешендә хокуклары чикләнми. Шуның белән бергә, күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтнең техник торышын ачыклау максатында вәкаләтле орган җирле үзидарә органыннан түбәндәге мәгълүматларны сорый: күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә чираттагы капиталь ремонт (норматив-ремонтара сроклар) уздырганчы конструктив элементлар һәм инженерлык системалары хезмәтенең норматив срокларын арттыру (арттырмау); күпфатирлы йортның конструктив элементларының ышанычлылыгының һәм иминлегенең билгеләнгән чик характеристикаларын бозу куркынычы булу (булмау) (3.4 пункт). Югарыда күрсәтелгән мәгълүматны үз эченә алган документларны алганнан соң, вәкаләтле орган аларны комиссиягә тапшыра (3.6 пункт).

739 номерлы тәртипнең шикаять белдерелә торган 3.7 пункты нигезендә комиссия алынган мәгълүматны анализлау нигезендә билгеләнгән срокта күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү кирәклеге турында (3.7.1 пункт) йә күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү кирәклеге булмау турында (3.7.2 пункт) бәяләмәне раслый һәм вәкаләтле органга тапшыра. Күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә чираттагы капиталь ремонт (норматив-ремонтара сроклар) уздырганчы конструктив элементлар һәм инженерлык системалары хезмәтенең норматив срокларын арттыру яисә арттырмау, шулай ук күпфатирлы йортның конструктив элементларының ышанычлылыгының һәм иминлегенең билгеләнгән чик характеристикаларын бозу куркынычы булу яки булмау тиешле карарны кабул итү нигезе була. Капиталь ремонт үткәрү кирәклеге турында бәяләмәдә күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү буенча башкарылырга тиешле хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) эшләр башкару төре һәм сроклары күрсәтелә.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программада каралган хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең срогын иртәрәк чорга күчерү турындагы мәсьәләне карау өчен 739 номерлы тәртипнең 3.1 пункты тәртибендә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар, күпфатирлы йорт белән идарә итүче оешмалар, әлеге нормада беркетелгән документлар пакетын кушып, вәкаләтле органга мөрәҗәгать итә ала дигән нәтиҗәгә килә. 739 номерлы тәртипнең 3.7 пункты эчтәлегеннән күренгәнчә, капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программада каралган хезмәт күрсәтүләрнең һәм (яисә) эшләрнең срогын иртәрәк чорга күчерү турындагы карар капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программада билгеләнгән срокларга караганда иртәрәк срокларны билгеләп йә капиталь ремонтны иртәрәк срокларда үткәрү кирәклеге булмау турында капиталь ремонт үткәрү кирәклеген билгеләү турында бәяләмә рәвешендә рәсмиләштерелә. Комиссия тарафыннан расланган бәяләмә вәкаләтле орган боерыгы белән рәсмиләштерелә, ул капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программаны актуальләштерү эшләрен оештыру өчен һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программага үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертү өчен нигез булып тора (4.1 һәм 4.4 пунктлар).

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 30 сентябрендәге 739 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау зарурлыгын билгеләү тәртибенең 1.2, 3.1 һәм 3.7 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләре, алар тарафыннан беркетелгән хокукый җайга салу кысаларында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программада билгеләнгән срокларга карата капиталь ремонт үткәрү срогын иртәрәк чорга күчерү хокукын гамәлгә ашыру мөмкинлеге билгеләнгән дәрәҗәдә кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын, шул исәптән гражданка Г.Ж. Галимжанованың да хокукларын юкка чыгармыйлар, киметмиләр һәм башкача бозмыйлар һәм шуның белән Татарстан Республикасы Конституциясенә туры киләләр, дигән нәтиҗәгә килә.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләрне Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану максималь дәрәҗәдә норматив билгелелеккә һәм административ процедураларның да, шулай ук капиталь ремонт үткәрүне капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программада билгеләнгән срокларына караганда иртәрәк срокка күчерү зарурлыгын билгеләү турындагы мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча алар кысаларында кабул ителә торган карарларның да алдан әйтелгәнлегенә ирешү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан хокукый җайга салуны камилләштерү мөмкинлеген кире какмый. Бу күчерүнең, процедура буларак, беренче чиратта торак законнары нормалары, шул исәптән Россия Федерациясе Торак кодексының 168 һәм 170 статьяларының кайбер нигезләмәләре белән беркетелгән аерым үзенчәлекләргә ия булуы белән бәйле. Әлеге нигезләмәләр хокукый җайга салуда үзенең чагылышын табарга тиеш, анда, шул исәптән, кирәкле документлар исемлеге, шулай ук алар кысаларында капиталь ремонт үткәрүне капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программада билгеләнгән срокларга караганда иртәрәк (соңрак) срокка күчерү кирәк булуы яисә кирәк булмавы турында нигезле һәм дәлилләнгән карар кабул ителерлек нигезләр ачыкланырга тиеш. Моннан тыш, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2020 елның 9 декабрендәге 758/пр номерлы боерыгы белән расланган Күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программага үзгәрешләр кертү турындагы карарларны Россия Федерациясе субъекты тарафыннан кабул итү буенча методик тәкъдимнәрнең нигезләмәләрен дә исәпкә алырга кирәк, аерым алганда, сроклар күчерелүгә бәйле рәвештә капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программага үзгәрешләр кертү өчен сәбәпләрне һәм нигезләрне регламентлый торган 5 пункт нормалары. Карала торган хокукый җайга салуга тиешле үзгәрешләр кертү Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрүне оештыру буенча гражданнарның мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча конституциячел әһәмиятле максатларга ирешүгә ярдәм итәр иде.

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә тулысынча туры килә, аның нигезендә закон чыгаручыга гражданга (гражданнар берләшмәләренә) алар белән үз тәртибен килештерергә мөмкинлек бирә торган җитәрлек дәрәҗәдә төгәллек белән хокукый күрсәтмәләрне формалаштыру бурычы йөкләнгән (2003 елның 27 маендагы 9-П номерлы, 2011 елның 31 мартындагы 3-П номерлы, 2013 елның 14 февралендәге 4-П номерлы, 2014 елның 17 июнендәге 18-П номерлы, 2015 елның 16 июлендәге 22-П номерлы һәм башка карарлар).

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 һәм 104 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү чиратын билгеләү критерие буларак, күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнәр түләүнең түләү дисциплинасын бәяләү өчен норматив нигез булып торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1132 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында күпфатирлы йортлардагы гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү чиратын билгеләү критерийларын файдалану тәртибенә кушымтаның 3.2 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 30 сентябрендәге 739 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау зарурлыгын билгеләү тәртибенең 1.2, 3.1 һәм 3.7 пунктларының үзара бәйле нигезләмәләрен, алар тарафыннан беркетелгән җайга салу кысаларында капиталь ремонт үткәрүне капиталь ремонт үткәрү буенча региональ программада билгеләнгән срокларына караганда иртәрәк срокка күчерү хокукын гамәлгә ашыру мөмкинлеге билгеләнгән дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 107-П

Татарстан Республикасы Конституция суды

922
2022
Идел буе Болгар дәүләтендә
Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы

БЕЗНЕҢ АВЫЛ ИМАМЫ

УТТА СЫНАЛГАН МӘЧЕТ

Олы кешеләрнең сөйләвенә караганда, безнең Түбән Утар авылы мәчетен Арча ягы Ашыт бае салдырган. Ул 40 ат белән агач тарттырып ташыткан, бөтен авыл халкы ярдәмгә килгән. Мәчетне төзеп бетергәч, халыкны аш пешереп сыйлаганнар.

Мәчеттә дин сабаклары укытылган. Балаларга Галиев Рашат абыйның әти-әнисе белем биргән. Соңыннан, укулар тәмамлангач, имтихан алганнар. Бу көнне әти-әниләрне дә чакырганнар. Биек сәкегә менеп басып, бөтен халык алдында «Мөхәммәдия»не көйләп укып күрсәткәннәр. Мәчет манаралы килеш 1939 нчы елларга кадәр мәктәп булып хезмәт иткән... «Түбән Утар авылы мәхәллә мәчете тарихы»нда шундый мәгълүмат тупланган.

Мин тәүге тапкыр белем алган, укытучы булып беренче хезмәт елымны башлап җибәргән мәктәп урынында хәзер манарасындагы аен балкытып, мәчетебез басып тора. Күңелгә якын изге йорт! Тирә-ягы чиста, заманча тимер рәшәткәле, бинасы да җыйнак кына, яшел төс бик килешә үзенә. Әнә болдыры...

«Әссәламугаләйкум вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!» – дип, Аллаһы Тәгаләнең сәламен җиткерде миңа йомшак тавышлы авылдашым Нәҗип Мәлик улы Кәримов.

Аның имам булып китүе болай була. 1996 ел. Авылда мулла юк. Аптырашка калган авыл халкы бу эшкә аны үгетли башлый. Бернинди белеме булмавын, бернәрсә белмәвен сәбәп итеп, каршы килә Нәҗип абый. Тагын ялваралар. Нишләсен инде, ризалаша.1999 елда, ниһаять, Казанга курсларга китеп, гарәп алфавитын өйрәнә. Намазга да баса. 1999 елның февраль аеннан имам вазыйфасына керешә.

Аянычлы вакыйга да була. Матур гына эшли башлагач, 2002 елның 20 декабрендә ут чыгып, мәчет янып бетә. Бер ел буе Газимулла абый Гыйззәтуллин өенә һәм башлангыч мәктәп бинасына җомга намазларына җыелалар. Ниһаять, 2004 елда кабат яңа мәчет сафка баса.

Ул арада Нәҗип абый Кукмара мәдрәсәсен тәмамлый. «Дипломлы имам булдым инде хәзер, иншаллаһ, шушылай итеп яшәргә язсын», – ди ул.

Безнең авыл халкы бик тырыш. Күркәм эшләре дә бар. Җитлекми туган балаларга бәйләнгән әйберләр кирәк була. Районыбызда эшләп килүче «Хәят» автоном коммерциячел булмаган оешмадан кешеләр килеп, йон җепләр калдырып китәләр. Тирә-як авылларны да уздырып, кеп-кечкенә Түбән Утардан 42 хатын-кыз әлеге изге гамәлдә катнаша... һәм 61 комплектлык җептән 82 комплект әйбер бәйли! Иң яшь бәйләүчегә – 25, иң өлкәненә – 81 яшь. «Зур хезмәт бит бу!» – ди, горурланып, авылыбыз имамы. Олысы-кечесенә Аллаһның рәхмәте булсын, дигән теләген дә җиткерде.

Авылның үткәне турында да үз кызыксынуы бар Нәҗип абыйның. Мәсәлән, «Ямьле Саба» проекты эшчәнлеге вакытында, районыбыз авылларына рейдлар ясала башлагач, әлеге очрашуда авылыбызның тарихы белән таныштыруны һәм «Бикә» чишмәсе турында аңлатып сөйләүне дә үз өстенә ала ул.

Авылыбыз халкына инде озак еллар медицина ярдәме күрсәтүче Гөлфия ханымны да мактап телгә алды имам. Ул абыстай булып тора. «Бик тәртипле, кешеләрне хөрмәт итә белгәнгә күрә, алар да аны хөрмәт итә, әлхәмдүлиллаһ», – диде ул. Үзенә дә хезмәтенең әҗерен күрергә язсын, Аллаһы Тәгалә гаиләсенә исәнлек бирсен. Шушы фани дөньяда һәммәбез дә иманлы булып гомер кичерсәк иде.

Сөмбелә ИБРАҺИМОВА.
Саба районы Яңа Мичән авылы

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЛАРЫ

Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары итеп вәкаләтләре чикләнмәгән срокка түбәндәгеләрне сайларга:

Татарстан Республикасы Баулы суд районы буенча:

2 нче суд участогына – Гатиятуллина Светлана Миргариф кызын;

Татарстан Республикасы Саба суд районы буенча:

1 нче суд участогына – Нәбиуллин Руслан Рамил улын.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 14 июле
№ 1513-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз өченче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утыз өченче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 316-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
3. «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 318-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 301-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
5. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 310-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү турында» 311-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасы Җир кодексының 32 һәм 32^1 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 317-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 313-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында» 314-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 315-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. Татарстан Республикасы Әлки районы Сиктерме-Хузангай авылының исемен үзгәртү турында.
12. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 20.1 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
13. «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» Федераль законның 10^6 һәм 15^{1-1} статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы хакында.
14. Авыл җирендә һәм шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга өченче бала туганда бер мәртәбә түләүне билгеләү кирәклеге турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мөрәҗәгате хакында.
15. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетының 2019 елның сентябреннән 2022 елның июленә кадәр эше турында хисап.
16. Педагогик эшчәнлекне гамәлгә ашыручы затларга картлык буенча иминият пенсиясен вакытыннан алда билгеләү хокукын бирә торган эш стажына исәпләнә торган эш вазыйфалары исемлегенә физик культура буенча инструктор вазыйфасын кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Урынбасары Т.А. Голиковага Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең мөрәҗәгате турында.
17. Белем бирүнең мәктәп системаларын модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе мәгърифәт министры С.С. Кравцовка Архангельск өлкә Собраниесе депутатларының мөрәҗәгате турында.
18. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 166^1 һәм 236^1 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 149518-8 номерлы федераль закон проекты хакында (Федераль казначылыкка тупланма пенсияне финанслауга иминият кертемнәре акчаларын һәм мәҗбүри пенсия иминияте резервын урнаштыру вәкаләтләрен беркетү турында).
19. «Кулланучылар хокукларын яклау турында» Россия Федерациясе Законының 4 статьясына һәм «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүматны саклау хакында» Федераль законның 10^6 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 149602-8 номерлы федераль закон проекты хакында (бердәм кушымталар кибете булдыру өлешендә).
20. «Россия Федерациясендә махсус икътисадый зоналар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 150776-8 номерлы федераль закон проекты турында (концессионерның махсус икътисадый зонада җир кишәрлеге алуга өстенлекле хокукын билгеләү өлешендә).
21. «Россия Федерациясенең Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 150793-8 номерлы федераль закон проекты хакында (капиталь ремонт программасын гамәлгә ашырганда күпфатирлы йортны техник тикшерү өлешендә).
22. «Юл хәрәкәте иминлеге турында» Федераль законның 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 127171-8 номерлы федераль закон проекты турында (Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы гражданнары тарафыннан турыдан-туры транспорт чаралары белән идарә итүгә бәйле эшкуарлык һәм хезмәт эшчәнлеге башкарылганда, бу республикаларда гамәлдә булган машина йөртү таныклыкларын тану хакында).
23. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 17.3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 127321-8 номерлы федераль закон проекты турында (судьяның яисә суд приставының судлар эшчәнлегенең билгеләнгән тәртибен тәэмин итү буенча күрсәтмәсен үтәмәгән өчен административ җаваплылыкны көчәйтү хакында).
24. «Юл хәрәкәте иминлеге турында» Федераль законның 23 һәм 28 статьяларына һәм «Персональ белешмәләр турында» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 149503-8 номерлы федераль закон проекты турында (транспорт чараларын йөртүчеләргә чираттан тыш мәҗбүри медицина тикшерүе үткәрү системасын камилләштерү хакында).
25. Хөкүмәт сәгате: «Экология» илкүләм проекты составына керүче «Иделне чистарту» федераль проектын Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру турында».
26. 2022 елның беренче яртыеллыгында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.
27. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 14 июле
№ 1512-VI ДС

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан агросәнәгате ветераннар Советы, абыйсы
Наил Шәһәретдин улы ЗИАТДИНОВ
вафат булу сәбәпле, «Татпродовощпром» җитештерү-коммерция концерны җитәкчесе Раил Шәһәретдин улы Зиатдиновның, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Авыл токтасы

Мин Әлмәт районы Елховой дигән мишәр авылыннан Сәхаб улы Тәлгать бабагыз булам. Бабагыз дигәнгә хәтерегез калмасын, миңа март аеның 25 нче числосында 85 яшь тулды, 86 нчыны башладым.

Авылыбыз зур, 300ләп йорт санала, ләкин еллар узу белән, буш йортлар күбәя бара. Безнең кебек картлар, төрле сәбәпләр аркасында яшьләр дә ахирәт сәфәренә күчә торалар, үземнең дә Илфак һәм Илһам улларым, җәмәгатем Галия ахирәткә күчтеләр, урыннары җәннәт түрләрендә булса иде. Кызым Кадрия, киявем Айрат, оныгым Дамир Әлмәттә яши, шуларның хәл-әхвәл белергә кайтуларын көтеп, берүзем яшәп ятам. Биш вакыт намазымны укып, шуннан көч алып шөкер итәм.

Авылыбызның имамы Искәндәр Мәхмүт улы Фәсхетдинов – дини гаиләдә тәрбияләнгән бала. Ул башта безнең авылыбызда клуб мөдире булып эшләде. Әти-әнисе намазда булгач, үзендә дә дин тоту теләге уянгач, Казаннан дини белем алып кайтты. Аннан соң инде авылыбызда имам булып сайланды.

Искәндәр хаҗиның бер күркәм гадәте бар: ул туктаусыз эзләнүдә, белем эстәүдә. Читтән торып югары белем алды да мәктәптә балалар укыта, гарәпчә укырга-язарга да өйрәтә. Мәктәптән соң теләге булган балалар, мәчеткә килеп, ислам дине сабаклары ала. Бу бит – кечкенәдән күңелгә иман орлыгы салу дигән сүз. Мәчеттә дә үз вазыйфасын төгәл башкара. Нәкъ башка авыллардагы кебек үк, җомга, гает намазларын укыта, барлык мөселман йолаларын башкара, мәчетне, зиратны тәртиптә тота.

Искәндәр хаҗиның гаиләсе дә күркәм. Алар Гөлфия ханым белән мәдрәсәдә танышып өйләнешәләр. Алты баласы да әти-әнисе кебек үк тыйнак, күркәм холыклылар.

Инде Аллаһ йорты турында. Мәчетебез карт безнең, совет заманында манарасы киселеп, башлангыч мәктәп булып торды. Без барыбыз да шул мәктәптә укыдык. Әүвәлге төзекләндерү эшләре Борһани улы Мәгъсүм хаҗи ярдәме белән башкарылды, мәдрәсә дә аның тырышлыгы белән булдырылды, урыны җәннәттә булса иде, 102 яшендә вафат булды. Икенче төзекләндерү эшләре Искәндәр хаҗи тырышлыгы белән эшләнде. Хәзер мәчетебез матур, килешле.

Мәчет манарасыннан бөтен авылга ямь өстәп, биш вакыт намазга чакырып азан әйтелә. Мәчетебез янәшәсендәге мәдрәсәнең ишекләре һәрвакыт ачык. Искәндәр хаҗи октябрь башыннан кыш буе ир-егетләрне укытса, хатыны Гөлфия ханым кышын хатын-кызларга сабак бирә. Менә инде 15 еллап булыр, мәдрәсәдә рамазан ае кергәч, Искәндәр хаҗи ифтар мәҗлесләрен башлап җибәрә. Аллаһ аның гаиләсенә иминлек, саулык, күңел тынычлыгы насыйп кылса иде.

Авылның токтасы диләр андый кешеләр турында. Безнең авылыбызның токтасы ныклы, өметле.

Барчагызга да Урал таулары чаклы сәлам.

Тәлгать СӘЛАХОВ.
Әлмәт районы Елховой авылы

Илдар Мөхәммәтҗанов

Матур яшәде, матур китте

Бу язманың герое, мин язып тәмамлаганчы, тиз генә, җиңел генә якты дөньядан китеп барды. Башта икеләнеп калсам да, соңыннан яхшы күңелле бабай турында күбрәк кешегә сөйлисем килеп, тәвәккәлләргә булдым. Якты истәлек булып калсын, искә алуым дога булып барсын.

Якупов Назыйф Шәехҗан улы 1931 елның 15 декабрендә Тәтеш районы Кызыл Тархан авылында гаиләдә өченче бала булып дөньяга килә. Аңа 10 яшь тулганчы сугыш башлана. Әтисе һәм олы абыйсы сугышка китәләр. Авылдагы бөтен эш хатын-кызлар һәм балалар җилкәсенә төшә. Назыйф бабай да бик иртә тәртә арасына керә. Чөнки өйдә биш бала, аларны ашатырга, киендерергә, кышка утын хәзерләргә кирәк. Ул әнисенең уң кулы була. Унөч яшендә инде олылар эшли торган эшләрне ышанып тапшыралар.

«Сөрдек тә, чәчтек тә, урдык та, бригадир кая кушса, шунда эшләдек. Бервакыт эшкә бик ябык, ак ат биргәннәре хәтердә. Мескен ат, хәле бетеп, буразнага яткач, мин дә аның янына сузылып яттым. Икебез дә азрак хәл алгач, торып китә алдык. Ач, ялангач булсак та, зарланмадык, Җиңү көнен тизрәк якынайту өчен көнне төнгә ялгап эшләдек», – дип сөйләгән иде Назыйф бабай.

2000 елның 9 июлендә авылыбызда шатлыклы вакыйга булды – яңа мәчет ачылды. Назыйф бабай шул көннән бик шатланып мәчеткә йөри башлады. 2013 елда аны имам итеп куйдылар. Шуннан бирле Назыйф бабай җанын-тәнен биреп эшләп йөрде. Олысы белән дә, кечесе белән дә уртак тел таба белде, кеше белән бик гади сөйләште. Һәр җомга саен азан әйтеп, намаз укыдылар. Балалар да бик теләп йөрде. Мәчетне төзекләндереп, чиста-пөхтә, тәртиптә тотты. Ураза тотучы кешеләргә, инвалидларга гает саен күчтәнәч таратты. Сөннәткә утырткан балаларны да буш калдырмады. Һәр ел саен өмәләр оештырып, зиратны тәртипкә китерделәр. Ул бу эшләрне чын күңелдән башкарды.

2018 елда Назыйф бабай хаҗ кылу бәхетенә иреште. Бу вакытта аңа 87 яшь иде. Бабай хаҗга барыр алдыннан 1–2 ай кала һәр көнне 3 чакрым йөреп кайта иде. Болай да җиңел гәүдәле бабай олы сәфәргә әнә шулай әзерләнде.

Бабайның бүген 5 баласы, 9 оныгы, 13 оныкчыгы бар. Аларның һәммәсе дә дин юлында, бик тәртипле балалар. Назыйф бабайларның өйләренә керсәң дә, ниндидер нур, җылылык бөркелә.

Уенын-чынын бергә кушып, әле 95кә кадәр яшим, дигән Назыйф бабай кинәт кенә китеп тә барды. Ләкин әле ул Җиңү көнен каршыларга, гаетне уздырырга өлгерде. Җомга көнне үзенең мәңгелек йортына кереп ятты. Матур яшәде, матур китте, дип авыл халкы озатып калды. Урының җәннәттә, рухың шат булсын, Назыйф бабай. Синең юлыңны дәвам иттерүче күпме оныгың гына бар. Авыл халкы сине онытмас, мәчеткә эзне суытмас.

Наилә ӘБЕЛХАНОВА.
Тәтеш районы Кызыл Тархан авылы

ЧАЛПЫНЫҢ ЧАЛ ТАРИХЫ

Авылыбыз өстендә яңгыраган моңлы азан тавышыннан җаннарга илаһи нур агыла. Мәчетебез имамы Зөфәр хәзрәт һәр көнне әнә шулай биш вакыт намазга чакыра. Рухи тәрбиячебез булып 30 ел халыкка хезмәт итә ул.

Дини уку йортлары – мәдрәсәләр ачыла һәм мәчетләр каршында укулар оештырыла башлагач, Хәйбрахманов Зөфәр Әнвәр углы да Азнакай мәчете каршында Шәрәфиев Кәшиф хәзрәттә башлангыч дин белеме алырга йөри башлый. Аны тәмамлагач, Октябрьск шәһәрендәге «Ислам нуры» мәдрәсәсендә Госман хәзрәт Исхакыйда белем ала. Шулай итеп, гыйлемле яшь егет, Чалпы мәхәлләсе картлары үтенече буенча, авылыбызга имам булып кайта.

1989 елларда «Коммунизмга» күмәк хуҗалык җитәкчесе Илдус Гыйләҗев, авылның кул осталары Гәрәев Касыйм һәм Фазлыев Әсгать ярдәме белән авылда һәм Азнакай районында 1944 елдан соң беренче манараны ясап күтәрәләр. Аны элек урта мәктәп, аннан соң сырхауханә булган бинаның урам ягына урнаштыралар. Шулай итеп, авыл картлары, җыелып, җомга намазы укый башлый.

Советлар Союзы таркалганнан соң, мөселманнар үз төбәкләрендә Мөфтиятләр төзи. Татарстанда да аерым Мөфтият төзелә һәм аның беренче мөфтие итеп Галиуллин Габдулла хәзрәтне сайлап куялар. Шулай итеп, Татарстан җирлегендә мәхәлләләрне теркәү башлана. Чалпыда да мәхәллә җыелышы булып, анда яңа укып кайткан Хәйбрахманов Зөфәр хәзрәтне имам-хатыйп итеп сайлап куялар, мәхәлләне теркәтү эшләрен дә аңа йөклиләр.

1998 елны яңа мәчет төзү хакында да сөйләшүләр алып барыла. 2001 елның җәендә яңа мәчетнең нигезе салына. 2008 елның 10 октябрендә авылыбызда тантаналы рәвештә яңа мәчет ачыла. Мәчеткә Чалпы авылының бишенче мәхәлләсе мулласы булган (1894–1944) акыл иясе Гыйрфан хәзрәт Вәлиуллин хөрмәтенә «Гыйрфан» исеме бирелә.

Зөфәр хәзрәт 1994 елдан бирле ислам дине нигезләрен өйрәнергә теләүчеләр өчен мәчет каршында укулар оештыра. Һәр елны мәктәп балалары һәм өлкәннәр дәресләргә бик теләп йөриләр, укырга теләүчеләр саны көннән-көн арта бара. Беренче көннән үк укуга йөргән Исламова Нурия абыстай хәзер үзе һәр елны өлкән хатын-кызларны укыта һәм оештыру эшләрен, финанс эшләрен алып бара. Илһамия абыстай һәм Гөлшат абыстайлар – мәчетебездә узган барлык чараларны оештыруда актив ярдәмчеләр. Районыбызда иң беренче корьәнхафиз булган Мансур хәзрәт тә – Зөфәр хәзрәтнең шәкерте.

Тарихка күз салсак, 1917 елгы Октябрь түнтәрелешенә кадәр Чалпы авылы иң зур – 6 мәчетле, 6 мәхәлләле авылларның берсе булган. Һәр мәчеттә патша Указы алган имамнар, мәзиннәр эшләгән. Алар, мәдрәсәләр ачып, шәкертләргә дин белеме биргәннәр.

Авылыбыздан элекке заманнарда зур һәм мәртәбәле дин эшлеклеләре чыккан. Тарихта билгеле булган атаклы Ногайбәкләр нәселе безнең авылда яшәгән һәм имам булып торган. Ногайбәкнең Шәмсетдин исемле улы ахун булган.

Әдәбият тарихында билгеле урын биләүче галим, мәгърифәтче, шагыйрь, дин әһеле, «Рисаләи Газизә», «Тәварихы Болгария» әсәрләрен язучы Таҗетдин Ялчыгол да (1768–1838) Чалпы авылында туган. Уллары Баһаветдин, Җәләлетдин, Шәрәфетдин указлы муллалар булган.

Мәшһүр татар галиме, җәмәгать һәм дин эшлеклесе Ризаэддин Фәхретдиннең «Асар» дип аталган китабында да безнең авыл муллалары турында мәгълүмат күп.

Хәзерге көндә рухи таянычыбыз булган Зөфәр хәзрәтнең дә имам булып китүенә XIX гасыр урталарында Чалпы авылының 3 нче мәхәлләсендә имам һәм мөдәррис булып хезмәт иткән Гыйльман хәзрәтнең («Асар» китабында аның нәселе турында языла) аның ерак бабасы булуы да этәргеч биргәндер.

Мондый гыйлемле, зыялы кешеләрнең безнең авылдан булуы күңелләргә нур, горурлык хисләре өсти.

Бүген без, Чалпы авылы халкы, зур горурлык хисләре белән, без бәхетле, дип әйтә алабыз. Чөнки безнең олы җанлы имамыбыз бар. Үз авылыбызда туып-

үскән, 1990 нчы елларда беренчеләрдән булып дини белем алган, 32 яшьтән башлап, авыр елларда да әби-бабаларыбыз күз карасыдай саклаган дини йолаларыбызны, гореф-гадәтләребезне дәвам иттерүче, авыл өлкәннәрен, яшьләрне дөрес юлга юнәлтүче имам-хатыйб Зөфәр хәзрәтебез бар. Әти-әниләре Нәҗибә апа һәм Әнвәр абый Хәйбрахмановларга улларына динебезгә дөрес караш тәрбияләгәннәре өчен бик рәхмәтлебез.

Вәзимә САФИНА.
Азнакай районы Чалпы авылы



ХА-ХА-ХАНӘ



Шушы урында көләсе

Галуштан карый дүрт дус – Гали, Вәли, Шәвәли һәм иң кечкенә дус Илдус!

Всё выключено

Элек Төркиядә «все включено»да ял итә идек. Быел авылда «все выключено»да ял итәбез.

Җәй ул – эшкә барган арада коияшта кызыну чоры.

«Ничек туйганымны белсәгез...» (сызып ата). «Берегезне дә күрәсем килми...» (сызып ата). «Хөрмәтле Гали Вәлиевич! Мине ялга җибәрүегезне сорыйм...»

Төреләрнең бик тә Россияне күрәселәре килә икән. Шундый итеп ял итәрлек нәрсә эшләп арыйлар икән алар үз илләрендә, дип баш ваталар ди.

Без йөргән кызым белән быел Мисырда ял иттек. Миңа ошамады. Берәүгә дә киңәш итмим. Әллә нәрсә шунда. Ачу китерүче кыз булып чыкты.

Узган елларны без Европага акча бүлмаганга йөрми идек. Быел – Европа ябык булганга.

Хатын белән ял акчаларын сандык та, без әле быел әллә ни арымадык та кебек шикелле сыман тоелды.

– Ишеттеңме, быел Краснодар краенда курорт түләве кертмәкчеләр ди.
– Тукта, ә Краснодар гаишниклары нәрсә җыя иде алайса?

Әгәр дә хатын-кыз диетага утырып, корсагына пресс ясый башлый икән, димәк, ике сәгатьтән аның диңгезгә китәсе бар.

ЧӘЧӘКЛЕ КЫЗЫКЛАРЫ

Күмергә бастырганнар

Элек, шырпыга кытлык заманда, авылларда мич тергезеп җибәрү өчен, морҗаларыннан төтен чыккан күшеләргә утлы күмер сорап керә торган гадәт булган.

Хәзерге Чәчәкле авылы, заманында Яңа Рәҗәп дип йөртелгәндә, Түбән урамында яшәгән Фатыйма апа улы Рәшиткә чуен тоттырып, урам аркылы гына торган Нургаяз бабай белән Бибигайшә апага кертеп җибәргән. Ни сәбәпледер, аларның күмер бирәселәре килмәгән. Шуңа ачу итеп, Рәшит боларның өйалды ишеген шул тирәдә генә эленеп торган йозак белән бикләгән дә чыккан. Әлбәттә инде, бу хакта әнисенә берни әйтмәгән.

Мескен карт белән карчык ике көн беркая чыга алмаган. Ярый әле өйләрендә запас утын белән флягага тутырган сулары булган. Урамда кыш бит, өй тәрәзәсен ачып бакчага чыгар иден, икенче кат рам куелган. Ишекне Нургаяз бабайның шәһәрдән кайткан улы Габдерәфыйк ачып кергән.

Шуннан соң Рәшитнең үзен дә «утлы күмергә бастырганнар».

Тәлгать МАНСУРОВ

«Күке белеп кычкырган...»

Таксида Казанга киттек. Машина тулы. Арттагы утыручы ялгызын түздырып бәйләгән ике татар әбие сөйләшеп бара:

– Чәчәкледә дә халык кимиме соң?
– Бетә шул, бетә, рәте белән буш йортлар тезелеп китте!
– Ни галәмәттер инде бу, авыр сугыш елларында да авыллар халык саны кубрәк иде. Хәзер әнә тормышлар да зарланырлык түгел, пенсияне вакытында бирәләр, кибет тулы ризык. Әмма яшәргә кешесе бетеп бара.
– Мин аның шулай буласын алдан белеп тордым, кешегә генә әйтәсе килмәде...
– Күрәзәче түгелсеңдер ич?
– Причем монда күрәзә? Берзаман Чәчәклегә күкеләр иялаште. Таң атуга килеп җитәләр. Башта авыл кырыендагы агачларга куныл кычкырдылар, аннары – ферма тирәсендә. Сөйләшеп куйганнар диярсең. Юньлегә түгел бу, дип эчем пошып йөргән иде. Шуннан соң дүрт-биш ел үтмәде икән, башта ил таркалды, аннан калхузларны таратып, фермадагы малларны юкка чыгардылар. Авылдагы яшьләр калага китеп бетте. Күкеләрнең хәзер тавышлары ишетелми. Алар да таралып беттеләрме икән әллә?

Минем дә авылдагы дуңгыз фермасы тирәсендә иртә таңнан күке кычкыруның ишеткәнем булды. Шуннан соң дуңгызларны каядыр озаттылар, таштан төзегән биналарны да сүтеп бетерделәр. Күке барысын да алдан хәбәр иткән икән, тыңлый гына белмәдек.

Аягы авыр, күзе каты...

Кая да булса барырга җыенып чыккач, сулы чиләк күтәргән кеше очраса – юлыбыз уңарга тиеш, дип шатланабыз. Ә инде буш чиләкле берәү куренсә – кайгырабыз. Борчылырга мәҗбүр итә ала торган башка кешеләр дә була икән әле.

Элек безнең күршедә бер апа яшәде. Урманга утынга киткәндә шул хатын очраса, йә арба, йә трактор көпчәге тишелә, саламга яки печәнгә баручыларның арканы өзелеп яки бастырыгы сынып, олавы ава торган иде. Аның аягы авыр, диделәр. Шуның өстенә әле күзе дә иләмсез каты булды шул апаның. Күз карашы белән гөлләрне корыта алды, күп саудыра торган сыерны сөтсез калдырды. Каян килде икән аңа шулкадәр тискәре энергетика? Бер эштән дә курыкмады үзе. Аягы авыр, күзе каты булганга, башка хатыннар бик үк өнәп тә бетермәделәр үзен. Аеруча трактор-машина белән эшкә баручылар аны ерактан әйләнеп узарга тырышты.

Иң кызыгы шунда: ул тулы чиләкләр белән очраганда да, юлга кузгалган машинаның авылдан чыккач ватылып кала торган гадәте бар иде.

Апа инде күптән вафат. Җинел сояклә иде ул үзе, тик аягының «авыр», күзенең «каты» булуы белән күпләрнең хәтерендә әле дә саклана, тормышта андыйлар да кирәк, дип, сагынып искә алабыз.

Тәлгать ҖАМАЛЕТДИНОВ

Чәчәкле – Спас районындагы авыл

БУЛМАС ДИМӘ...

Мәзәкләр тормыштан алына, диләр. Кайвакыт көндәлектә шундый хәлләр була: мәзәктән дә болайрак. Аста бәян ителгән хәлләр чынлыкта булган. Һәрхәлдә, аны сөйләгән кешеләр шулай ди.

* * *

Бер хатын бик стресслы эштә эшли. Өстәвенә өендә дүрт баласын карыйсы бар. Эштән соң өйгә кайтыр алдыннан әлкән кызы белән кибеттә кассага чират тора болар. Җитмәсә, артта торган сәрхүш бер ир-ат төрле юкбар сораулар белән бәйләнә. «Тимәгез миңа, ди хатын. Шунда кызы әйтеп куя: «Әни, син анда эшлим дип әйт инде, аңлатып сөйләш, әллә ни уйлаулары бар».

* * *

Бәхетле туристлар Төркиягә очарга җыена. Аэропортта чират. Таможняда кемдер талаша. Гаилә башлыгы, нәрсә булды икән дип, чиратның башына барып карый. Ә анда бер хатын самолет эченә шешә алып кермәкче була икән. Шешә эчендә боз. Әмма хатынны үткәрмиләр. Кагыйдә буенча самолет эченә сыекча алырга ярамый. «Ә бу сыекча түгел!» – дип тарткалаша хатын. Ахыр чиктә боз барыбер Төркиягә оча алмый кала, якынрак җиргә оча – яңашәдә торган чүп чиләгенә.

* * *

Бушлай игъланнар сайтында бер апа микродулкынлы мич сатмакчы булган. Ниһаять, алучы табыла! Алдан шалтыратып, өйгә ике егет килеп керә. Күренеп тора: Якын Көнчыгыш якларыннан килгән эшчеләр. Тауар эшлиме-юкмы иканен башта тикшереп карарга кирәк бит. Егетләр үзләре белән алып килгән ризыкны микроволновкага тыгып куялар. Бер минут көтәләр, ике минут... Аннары чың иткән тавыш ишетелә. Җылынган! Димәк, микроволновка яхшы эшли. Егетләр рәхмәтләрен әйтәләр дә чыгып китәләр. Ризык җылыту гына булган икән максатлары.

Төш, син бит тау кәҗәсе түгел!

Мач әйткән!

Дэн СЯОПИН:

Тычкан тота торган мәченең нинди төстә булуы мөһим түгел!

Ир – баш, хатын – муен

– Хатынымның беренче ирен эзлим.
– Нәрсәгә ул сиңа?
– Ул ир ничек качкан икән аннан, шуны беләсем килә.

* * *

– Кичә күрше кызына шкаф күчерергә ярдәм иткән идем. «Ой, син шундый ярдәмчел, мин синә кияүгә чыгар идем», – ди. Кара инде син бу хатын-кызларны! Син аларга ярдәм итәсең, ә алар сиңа шундук яный башлый!

* * *

Кыз: Сөйгәнемне ничек кире кайтарырга?
Хатын: Иремне ничек әнисенә кире кайтарырга?
Әби: Сталинны ничек кире кайтарырга?

* * *

Бөтенегез интернеттан чыгып торыгыз әле, бераз ялгыз каласым килә.

* * *

– Әнием, таныш бул: бу – Лилия.
– Бәтәч, син эт алырга чыгып киткән идең түгелме соң?

* * *

– Хатын! Син минем белән кибеттәге кассир сыман салкын сөйләшәсең! Мин синнән чыгып китәм!
– Пакет кирәк буламы?

Әз-мәз мәзәк

Мөгаен, сезнең танышларыгыз арасында шундый яшь пар бардыр: алар балаларына исем сайлаганда сезнең исемне искә алып, «ой, юк» дип әйтеп куйганнардыр.

* * *

Инструктор:
– Беренче кагыйдә: урманга кечкенә кыңгыраулар алып барыгыз. Икенче кагыйдә: аю күрсәгез, кечкенә кыңгырауларны яңгыратып, аюны куарга тырышыгыз. Өченче кагыйдә: урманда аю кәкәе күрсәгез, ул җирдән ерграк китәргә тырышыгыз.
– Абый, ә аның аю кәкәе икәнен ничек аңларга?
– Анда кечкенә кыңгыраулар күп булыр.

* * *

Тычканның кайсы җиренә укол ясама – ул барыбер «внутримышечный» булачак.

Кыскалыкта – осталык



– Йөгез, әйдә, егетләр, шул хөрмәткә!
– Йөгез, әйдә, шул хөрмәткә!
– Йөгез, шул хөрмәткә!
– Йөгез!
– Йә!

Дусларча шарж

Элвин Грей дигән егет бар,
Нәрсә диган сүз ул – «грей»?
Инглизчәдән тәрҗемәсе
Соры була икән, бәй!

Карап-карап тордым моңа,
Тагын бер кат карадым.
Кай җирен соры соң синең?
Кайсы җирең «грей», наным?

Наил Галимов шаржы

Кайный Казан

vk.com

➢ Кызлар, сезгә әйтәм: егетне Казанның башка районыннан сайлагыз. Җәй көне җылы су берегезгә булмаса, икенчегездә булыр.

➢ Бары тик Казанда гына автобус тукталышлары мондый тәртиптә урнаша ала: «Солнышко», «Дружба», «ЗАГС», «Роддом».

➢ Мин, яңа фатирга күчкәч, иң элек күршеләремне ошаттым. Шундый тынычлар. Коридорда берәү дә исереп йөрми мин шешәләр ташларга чыккан вакытта.

➢ Мин аңладым. Ял көнне кич Казаннан китәргә кирәк, ә җомга кич Казанга кайтырга. Шулай итсәң, юл бөкесенә эләкмисең.

➢ Казанда бер бүлмәле фатирдан ике бүлмәлегә күчәргә теләсәгез, белеп торыгыз: бер бүлмәле фатирга сыйган кирәк-ярак ике бүлмәлегә сыймаячак!

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Илфак ХАФИЗОВ

Кунакчыллык

Дуслар, әйтегез әле, чит ил кинолары караганыгыз бармы?.. Нигә ул киноларда, әгәр кунак килсә, «Гафу итегез, миндә кеше бар, башка вакытта кер инде», – дип борып җибәрәләр ул? Бичара болай да әллә кайлардан тилмереп килгән бит инде. Аннан бер стакан су да эчә алмый кире китә. Ике кунакны берьюлы кабул итеп булмыйммени? Күрәсең, алар таныш түгел, шуңа уйлыйсыз...

Ә менә безнең якта әйтми-нитми кунаклар кайтса... «Тукта әле, күрше, миндә кеше бар», – дип әйткәнче үк, «Кара инде боларны, кунаклар кайткан икән бит!» – дип, ярты авыл җыела. Танышмы, туганмы, әллә бөтенләй беренче тапкыр күргән кешеме – барыбер. Танышып, серләшеп ахирәттәй аерылышалар. Тик башта, 3-4 сәгать гәпләшеп, 5–6 чынаяк чәй эчкәч кенә. Иң кызыгы – беләсезме, нәрсә? Әнинең: «Әләй, улым, бернәрсәм дә юк бит, өстәлгә нәрсә генә куярмын инде?..» – дип әйтүе һәм аннан соң бер рота аштарлык тәмнүткәләр ташуы. Әгәр алдан хәбәр иткән булсаң, нишләр иде икән?.. Кайда ул чит илдә ярты авыл җыелу! Бер-ике күрше керсә дә аһ итәләр. Ә без – кунакчыл халык!

Айваз САДЫЙРОВ

Замана мәкальләре

Татар халык мәкальләре – үткен корал. Заманга җайлап, кайберләрен бераз гына үзгәртеп тә була кебек.

- Егет кешегә 70 төрле кредит та аз.
- Хәрәкәттә – бәрәкәт, интернетта кызыграк!
- Эзләгән табар... «Яндекс» белән «Гугл»да.
- Ана күңеле – балада, бала күңеле – «Айфон»да!
- Йөз дустың булганчы, йөз язылучың булсын.
- Бер блат мең бәладән коткара.
- Туры әйткән хакимияткә ярамаган.
- Кем эшләми, шул – Блогер!
- Эш беткәч, «Сони Плейстейшн»да уйнарга ярый.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының уртак каталогына кертелгән.

Тираж – 6640 данә
Гомуми тираж – 16052 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 301

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим итела.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Кучерен бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Баклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+